СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Куркачи ул. Клубная, 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур, 4

Тел./факс: +7(84365) 70-700 e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.05 2020 г.

КАРАР
№ 187

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче ел, 6 нчы октябре 131-ФЗ Федераль законы, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске-Казан авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Иске-Казан авыл җирлеге Советы тарафыннан расланган 2019 нчы ел, 21 нче октябре 167 нче номерлы Нигезләмәсенә (алда- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 һәм 2.5 нче пунктларда “(“1 нче кушымта») (“2 нче кушымта”), (“3 нче кушымта”)” сүзләрен “(үзара салым мисалында 1нче номерлы кушымта үрнәге”), “(“Үзара салым мисалында 2 нче номерлы кушымта үрнәге”)”, ; “(“Үзара салым мисалында 3 нче номерлы кушымта үрнәге”)” сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 2.9.2 нче пунктта “(“5 нче, 6 нчы номерлы кушымта”)” сүзләрен “(“Үзара салым мисалында 5 нче, 6 нчы номерлы кушымта үрнәге”)” сүзләре белән алыштырырга;

1.3. 3.1 нче пункттагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенны оештыручы тарафыннан теркәләләр һәм торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган затлар исемлеге белән чагыштырылалар.»;

1.4. 3.3. нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Сайлау хокукына ия булган, торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр килеп чыккан очракта, торак пунктта яшәүче кеше җыенга шәхесне билгеләү документлары булганда кертелә»;

1.5. 3.5. нче пунктта “муниципаль берәмлек башлыгы” сүзләрен “җыенда рәислек итүче” сүзләре белән алыштырырга;

1.6. 3.17. нче пунктта җәяләр эчендәге (14 нче номерлы беркетмә) сүзләрен җәяләр эчендә (14 нче номерлы кушымта) сүзләре белән алыштырырга;

1.7. 3.18 нче пунктта “җирлек башлыгы тарафыннан имзалана” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 3.21. нче пунктта “муниципаль берәмлек башлыгына” сүзләрен «җыенда рәислек итүче имзалавына» сүзләре белән алыштырырга;

1.9. 4.2. нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокук актлары булып торалар,

муниципаль берәмлек башлыгы яки җыенда рәислек итүче тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертелергә тиешләр»;

1.10. 4.5. нче пунктта «(үзара салым мисалында15 нче номерлы кушымта үрнәге)» сүзләрен өстәргә;

1.11. «Иванова Светлана Ивановна – ФАП мөдире», «Иванов Иван Ивановичны», «Петрова Полина Петровнаны» сүзләрен кушымтадан төшереп калдырырга

1.12. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 15 нче номерлы кушымта белән тулыландырырга:

Биектау муниципаль районы
Иске-Казан авыл җирлеге
Советының
20___нче ел,
________________
____________ номерлы
карарына 15 нче номерлы
кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге
____________________ торак пунктында граждannар җыены нәтиҗәләре

от __________ 20__ №___

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законының 25.1, 56 нчы маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 ел, 28 нче июле, 45-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" законы нигезендә 20___ елның "___" _______ , 00 сәг. 00 мин., 20___ елның"___"_______,00сәг.00мин. ________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
соравы буенча уздырылган халык җыены этаплары буенча беркетмә төзелде.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә ______ җыенда катнашучы гражданин теркәлгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны ______ кеше, бу _____% тәшкил итә .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ" позициясе өчен җыенда катнашкан ____ кеше тавыш бирде; «КАРШЫ" позициясе өчен җыенда катнашкан _____ кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең __________________ торак пунктында җыен булган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең _____________ авылы территориясендә теркәлеп яшәүче һәр балигъ булган кешегә _______ нче елда _______ сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне үтәүгә юнәлдерергә:

_______________________________________________________________

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә .

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _____________

______________________________________________________________________

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова

1 нче номерлы кушымта
Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының
2019 нчы елның ____________ ____
номерлы карарына

СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Куркачи , ул. Клубная, 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб ур, 4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
« ___» _____________2019 года

КАРАР
№____

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында

2003 нче елның, 6 нчы октябре 131-ФЗ номерлы “ Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы” Федераль Законы, 2004 нче елның, 28 нче июле 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турындагы” Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2017 нче елның, 13 нче апреле 711/ПР номерлы “Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәрнең эчке районнары территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрен раслау турында” Боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтага нигезле “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының “Иске-Казан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен расларга.
2. Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

2018 нче елның, 05 нчы июне  116 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында»;

2018 нче елның, 26 нче сентябре 127 нчы номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan.ru/. урнаштырып  халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлеше контролен үз өстемдә калдырам.

Совета рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Г.Р.Закирова

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның,
“_____” ____________ ______
номерлы Карары белән расланган
Кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү**
**Кагыйдәләре**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Черрнышевка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре (алда – Кагыйдәләр) 2003 нче елның, 6 нчы октябре 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы” Федераль Законында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында, әйләнә-тирә мохитне саклау турында, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге федераль законнары һәм башка Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының һәм муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Кагыйдәләр барлык физик һәм үзләренең оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә юридик затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

3.Әлеге Кагыйдәләр җирлекнең бөтен территориясендә гамәлдә һәм түбәндәге таләпләрне билгелиләр:

-биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын, әлеге биналар һәм корылмаларның фасадлары һәм коймаларының тышкы күренешен карап тору буенча;

-төзекләндерү эшләренең исемлеге һәм аларны башкаруның кабатлылыгына карата;

-төзекләндерүдә биналарның (алардагы урыннарның) һәм корылмаларның милекчеләренең катнашу тәртибен билгеләүгә карата;

-җирлек территориясендә төзекләндерүне оештыру буенча (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнарның исемнәре һәм номерлары күрсәткечләрен кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап торуны кертеп).

4. Территорияләрне төзекләндерү элементларын проектлаштыру һәм урнаштыру шәһәр төзелеше һәм җир турындагы законнар, махсус нормалар һәм кагыйдәләр, дәүләт

стандартлары, җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, тиешле тәртиптә расланган проект документацияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге Кагыйдәләр җирлек территориясендә көнкүреш һәм промышленность калдыкларын җыю, чыгару, транспортировкалау, утильләштерү һәм кабат эшкәртү буенча мөнәсәбәтләрне көйләмиләр.

**Төп төшенчәләр**

6. Әлеге Кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатыннан түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

җирле әһәмияткә ия автомобиль юлы – транспорт чаралары хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм үз эченә автомобиль юлына аеру полосасы чигендәге җир участокларын һәм аларда яки алар астында урнашкан конструктив элементлар (юл өслеге, юл катламы һәм шуңа охшаш элементлар) һәм аның технологик өлеше булган юл корылмалары, - саклагыч юл корылмалары, ясалма юл корылмалары, җитештерү объектлары, автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын үз эченә алучы транспорт инфраструктурасы объекты;

фасадның архитектура үзенчәлекләре – фасадның конструктив һәм эстетик сыйфатларын чагылдыра торган, әйләнә-тирә шәһәртөзелеш мохитеннән бинаның аерымлыгы характеристикалары (стиль һәм композиция бөтенлеге, ритм, размерга ярашлык һәм пропорциональлек, визуаль кабул итү, ачык һәм ябык пространстволар балансы);

фонсыз конструкцияләр – конструкциясе аерым хәрефләрдән, билгеләмә, билге, декоратив элементлардан торган тышкы мәгълүмат чараларын ясау алымы;

территорияне төзекләндерү – муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшырту һәм карап тоту буенча, торак пункт территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән территория янәшәсендәге гомуми кулланылыштагы территорияләрне, җир участокларын, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне карап тоту буенча гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын күтәрүгә юнәлтелгән, муниципаль берәмлек территориясенең төзекләндерү кагыйдәләре билгеләгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

вертикаль яшелләндерү – балконнарны, лоджияләрне, галереяларны, терәүле диварларны һ.б. да кертеп, биналарның һәм корылмаларның фасад өслекләрен аларга стационар һәм мобиль яшел утыртмалар урнаштыру өчен куллану;

витрина – фасадның бер өлешен алып торучы тоташ пыялаланган (тәрәзә, витраж) пыялаланган ачыклык;

барлыкка килгән төзелмәнең тышкы архитектур күренеше – җирлекнең тышкы образын хасил итүче бина фасадларының һәм җирлек территорияләренең архитектур-сәнгать һәм шәһәр төзелеше үзенчәлекләре;

тышкы яктырту алымы – мәгълүмат конструкцияләреннең мәгълүмат кырын читкә куелган яктылык чыганагыннан юнәлдереп яктырту алымы;

эчке квартал (җирле) юлы - траспорт һәм җәяүлеләрнең магистраль юлдан торак йортлар һәм кварталның башка урыннарына хәрәкәтләнү өчен каралган автомобиль юллары;

төзекләндерүне торгызу – үз эченә асфальт капламын бөтен юл киңлегенә, хуҗалык юлларын, тротуарларны сыйфатлы торгызу, бордюр ташларын кире урнаштыру, уңдырышлы туфрак катламын торгызу, газоннарны тырмалап газон үләннәрен чәчеп һәм яшел утыртмалар утыртып газоннарны ремонтлау, реклама конструкцияләрен һәм башка төзекләндерү элементларын торгызуларны үз эченә алган чаралар комплексы;

газон – утыртмалар, парк корылмаларына фон һәм ландшафт композициясенең мөстәкыйль элементы булып торучы махсус сайланган үлән орлыкларын чәчеп барлыкка китерелүче үлән катламы, шулай ук табигый үлән үсентеләре;

җирлек территориясе – муниципаль берәмлек чикләрендәге территория;

мәгълүматны тапшыруның динамик ысулы - мәгълүматны алмаштыруны күздә тоткан электрон йөрткечләр һәм табло куллану юлы мәгълүмат тапшыру ысулы;

йорт-җир – ишегалды корылмалары белән шәхси торак йорт һәм әлеге йорт урнашкан җир участогы;

ишегалды корылмалары – җир участогында урнашкан вакытлы ярдәмче корылмалар (баз, күгәрчен оялары, сарайлар һәм б.ш.);

йорт билгеләре - аншлаг (урам, мәйдан, проспект исемнәрен күрсәткеч), номер билгесе (йорт һәм корпус номерын күрсәткеч), подъезда һәм фатир номерын күрсәткеч, инвалидлар өчен объектның халыкара уңайлылык символы, флагтоткычлар, истәлек такталары, полигон үлчәү билгесе, пожар гидранты күрсәткече, грунт геодезик билгеләре күрсәткече, магистраль камералары һәм суүткәргеч челтәре коеларының күрсәткечләре, җирлек канализациясе күрсәткече, җир асты газүткәргече корылмалары күрсәткече;

бина – автономияле рәвештә тора, реконструкцияләнә һәм эксплуатаияләнә ала торган, үзе белән бердәм күләмле корылмалар системасын (төзелүгә бер рөхсәт нигезендә корылган) тәшкил итүче капиталь төзелеш объекты;

яшел утыртмалар – табигый яки ясалма утыртылган агач-куаклык һәм үләнле үсентеләр җыелмасы (парклар, урманнар, аеруча саклана торган табигый территорияләр, бульварлар, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәк клумбалары, шулай ук аерым торуча агач һәм куаклыклар);

җир участогы –шәхси билгеле әйбер сыйфатында аны билгеләргә мөмкинлек бирүче характеристикаларга ия булган җир өслегенең бер өлеше;

җир эшләре – җирлек территориясенең камилләштерелгән яки грунт катламын бозу белән, грунтны чыгару, урнаштыру белән яисә юлларның һәм тротуарларның камилләштерелгән өслеген урнаштыру (тезү) белән бәйле эшләр;

инженер коммуникацияләре – җирлек территориясендә булган яки корылучы инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре: суүткәргеч, канализация, җылыту, трубаүткәргечләр, элекр һәм элемтә үткәргечләр линиясе һәм башка инженер корылмалары;

җирлекнең тарихи территорияләре – үзләштерелүе XI гасыр башыннан 1956 нчы еллар аралыгына туры килгән һәм аларга карата тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларының куюга рөхсәт ителгән һәм ителмәгән төрләре һәм типлары, шул исәптән мондый конструкцияләргә карата таләпләр Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр), аларны саклау һәм файдалану турындагы Россия Федерациясе законнарына нигезләнеп билгеләнә торган җирлекнең махсус әһәмиятле территорияләре. Җирлекнең тарихи территорияләре гомуми чиге Башкарма комитетның муниципаль хокукый актлары белән раслана;

түбә яшелләндерү – биналарның һәм корылмаларның түбәләрен архитектура-ландшафт объектлары (газоннар, чәчәклекләр, бакчалар, агачлар һәм куаклар белән мәйданчыклар һ.б.) ясау өчен файдалану;

яңгыр канализациясе (ливневка) – җир өсте (яңгыр, җыелып торган), сиптерү-юу һәм дренаж суларын агызу өчен каралган инженер корылмаларының үзара технологик бәйләнештәге комплексы ;

җемелдәүче яктылык – яктылык агымының характеристикалары алмашын күздә тоткан яктылык-динамик эффекты (төс, ачыклык, тоташтыруының чиратлашуы һәм ш.б.);
тышкы яктырту – җирлекнең магистральләрен, урамнарын, мәйданнарын, паркларын, скверларын, ишегалларын һәм җәяүле юлларын тәүлекнең караңгы вакытында яктырту өчен билгеләнгән элементларның җыелмасы;

оешкан төзелмәнең тышкы архитектур йөзе бозылу – оешкан төзелмәнең тышкы архитектур йөзен саклау кирәклеген истә тотып, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларының тибы һәм төре, куелуының рөхсәт ителүе һәм ителмәве таләпләренең үтәлмәве;

санкцияләнмәгән чүплекләр – юридик һәм физик затларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән 50 кв.м дан арткан мәйданда һәм 30 куб.м дан артык күләмле үзбелдеге белән (санкцияләнмәгән) көнкүреш каты, эре габаритлы, төзелеш калдыкларын һәм башка чүпне ташлау (урнаштыру);

стационар булмаган сәүдә объектлары – инженер-техник тәэмин ителеш челтәренә тоташтырылуы (технологик тоташтыруга) булу яки булмавына бәйсез рәвештә җир участогы белән ныклы бәйләнмәгән вакытлы корылма яки вакытлы конструкция тәшкил итүче сәүдә объекты;

яшелләндерү – үсемлек компонентларын актив кулланып, муниципаль җирлек мохитен барлыкка китерүне тәэмин итүче төзекләндерү һәм территориянең ландшафт оешмасының элементы, шулай ук инженер әзерлегенең төрле төрләре буенча эшләр алып бару белән бәйле (вертикаль планировка, террасалау, кронлау һәм б.) һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерүнең комплексы процессы: турыдан-туры, шул исәптән эрекүләмле агачлар, куаклар утырту, үлән газоннары, чәчәклекләр, альпинарийлар һәм рокарийлар ясау, махсус бакчалар кору һәм б.ш.

гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләр – гомуми кулланылыштагы территорияләрдә урнашкан скверлар, парклар, бакчалар һәм бульварлар;

чикле кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләр – предприятие, оешма, учреждениеләрнең яшелләндерелгән территорияләре;

махсус билгеләнешле яшелләндерелгән территорияләр - санитар зоналар, сусаклау зоналары, зиратларны яшелләндерү, утыртмалар питомниклары;

аеруча саклаулы табигый территорияләр – аеруча табигый сак, фәнни, мәдәни, эстетик, рекреацион һәм сәламәтләндерү әһәмиятенә ия булган табигый комплекслар һәм объектлар урнашкан, җирле үзидарә карарлары белән тулысынча яки өлешчә хуҗалык файдалануыннан алынган һәм алар өчен махсус сак режимы куелган җир участоклары, су өслеге һәм алар өстендәге һава киңлекләре;

җәмәгать транспортын көтү тукталышлары – җәмәгать транспорты туклалышы өчен, пассажирларны утырту һәм төшерү зонасы һәм пассажирлар тарафыннан җәмәгать транспортын көтү зонасы булган махсус корылган мәйданчык;

пыялаланган фасад – фасадның бөтен яссылыгын яки аның әһәмиятле өлешен алып торучы тоташ пыялаланып эшләнгән фасад;

яктыртуның ачык ысулы –мәгълүмат конструкцияләрен яктырту ысулы, бу очракта яктылык чыганагының яктысы таралу өчен каршылыклар булмый;

җирлекнең күренеше – ачык пространстводан кабул ителә торган (яр буе, мәйдан, су объектларының акваториясе, күренеш һәм карау мәйданчыклары), җирлекнең сыйфатламаларын һәм силуэтларын ачучы җирлек территориясе өлеше;

биналарның фасадларының колористик чишелеш паспорты (фасадларның төсе чишелеше) – җирлек территориясендә урнашкан аерым торучы бина фасадының бердәм архитектур һәм төс чишелешен билгеләүче һәм аның тышкы бизәлешенә таләпләр куючы билгеләнгән тәртиптә килештерелгән һәм расланган документ;

җирлекнең урамнар перспективасы – урамнарның композицион, стиль һәм сәнгать сыйфатламалары белән оешкан алгы фронтын һәм силуэтын барлыкка китерүче җирлек мохитенең бер кисәген визуаль кабул итү;

җәяүлеләр зоналары – торак пунктында халыкның җәяүләп йөреп керү һәм мәдәни-көнкүреш максатларында, транзит хәрәкәт итүе гамәлгә ашырыла торган һәм билгеле бер сыйфатламаларга ия булган: урамныкы булмаган тизлекле һәм җир өсте җәмәгать транспорты тукталышлары булган, хезмәт күрсәтүче объектлар, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр, рекреацияләр һ.б. күпләп тупланган, җәяүле агымнарының суммар тыгызлыгы югары торган территория өлешләре. Җәяүле зоналары ачык урыннарда, җәяүле урамнарында, торак пунктындагы мәйданнарда җәяүлеләр йөри торган өлешләрдә формалашырга мөмкин;

йорт яны территориясе –чиктәш булып торучы яшелләндерү һәм төзекләндерү элементлары белән торак күпфатирлы йорт урнашкан җир участогы, әлеге йортка хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен күрсәтелгән җир участогында урнашкан башка объектлар;

тоташучы территория –Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртипкә туры китерелеп муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән чикләре билгеләнгән җир участогы булса, мондый җир участогына бинага, төзелмәгә, корылмага килеп тоташы торган гомуми кулланылыштагы территория;

продуктлы йорт хайваннары һәм кошлары — берничә тапкыр яки даими рәвештә сөт, йон, йомырка һәм башка продуктлар алу өчен кулланыла торган хайваннар һәм кошлар;

тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт) – төзекләндерү элементының, төгәлрәге тышкы мәгълүмат һәм аны идентификацияләү өчен кирәкле мәгълүматларны үз эченә алучы чараларын, тышкы күренешен һәм төгәл урнаштыру урынын билгели торган Башкарма комитет карары белән расланган билгеләнгән формалы документ;

территорияне санитар чистарту – билгеләнгән территориядән көнкүреш каты һәм эре габаритлы калдыкларны җыю, чыгару һәм утильләштерү (зарарсызландыру);

яктылык тартмасы – конструкциясе үзе белән эчке яктыртулы бердәм күләмле яки күләмле элементлар рәтен тәшкил итүче тышкы мәгълүмат чарасын әзерләү ысулы;

авыл хуҗалыгы хайваннары – терлекчелек яки башка авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү өчен хайваннар, терлек, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, кроликлар, бал кортлары һ.б.;

специальләшкән оешмалар – төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә торак пункт территориясен төзекләндерү өлкәсендә эшчәнлекнең махсус төрләрен гамәлгә ашыручы төрле оештыру-хокукый формалы юридик затлар ;

территорияләре карап тоту–җир участогында урнашкан биналарның фасадларын, корылмаларны, кече архитектур формаларын, коймаларны, төзелеш мәйданчыкларын, яшел утыртмаларны, җир асты инженер коммуникацияләрен һәм аларның конструкция элементларын, транспорт инфраструктурасы объектларын вакытында ремонтлау һәм карап тоту белән бәйле чаралар комплексы;

җирле әһәмияткә ия булган юлларны карап тоту – юлларның транспорт-эксплуатация халәте, юл корылмалары, юлларның комплекслы төзекләндерү элементлары хәлен саклап тоту буенча эшләр комплексы;

тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы (вывеска) – территорияне төзекләндерүнең бер элементы, “Кулланучыларның хокукларын саклау турындагы” Федераль законынның 9 нчы маддәсе кушканча, төгәлрәге оешманың фирма исеме (исеме), аның урнашу урыны һәм аның эш режимы, шулай ук закон кушуы буенча урнаштырылуы мәҗбүри яки эшлекле әйләнеш тәртибе буенча урнаштырыла һәм реклама максатларын күздә тотмаган мәгълүматка ия булган кулланучыларга мәгълүматны җиткерү өчен биналарны мәгълүмати бизәкләү максатларында оешма урнашкан һәм (яки) турыдан-туры товарларны сату урынында куела торган мәгълүмат конструкциясе. “Тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы” һәм “тышкы мәгълүмат чарасы” төшенчәләре тәңгәл;

суперграфика – күреп кабул итүне көчәйтә торган фасадларны архитектур-сәнгати бизәүнең бер алымы (рәсем, орнамент, барельеф, мозаика);

тактиль түшәмә – җир өслегендәге катлам фактурасын сизелерлек үзгәртә торган түшәмә;

махсус торак пункт әһәмиятендәге территорияләр –махсус статуска һәм (яки) югары мәдәни-рекреацион һәм социаль кыйммәткә ия булган торак пункт территориясенең кисәкләре, аларга карата торак пунктның оешкан төзелмәсенең тышкы архитектур күренешен саклау максатыннан әлеге Кагыйдәләр тарафыннан тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларының куелышы рөхсәт ителгән һәм ителмәгән төрләре һәм типлары, шул исәптән мондый конструкцияләрне урнаштыруга таләпләр куела;

территорияләрне җыештыру – җитештерү һәм куллану калдыкларын, башка чүпне, карны җыюга, калдыкларның махсус билгеләнгән урыннарына чыгаруга бәйле эшчәнлек төре, шулай ук халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән бүтән чаралар;

урамнар һәм гомум торак пункт юллары – гомуми кулланылыштагы территорияләр, аларның торак пункт мохите эстетикасына карата югары таләпләр куела;

вәкаләтле орган – үз компетенцияләре чикләрендә торак пункт территориясен төзекләндерүнең оештырылуын, юнәлешләрен һәм контролен гамәлгә ашыра торган Башкарма комитет;

фасад – бинаның тышкы ягы (төп, ян, ишегалды);

фон конструкцияләре – тышкы мәгълүмат чарасын хәрефләре, билгеләмәләре, декоратив элементлары фон өслегенә урнаштырылып ясала торган алым;

фриз – горизонталь полоса рәвешендә фасад яки козырекны әйләндереп алган декоратив элемент;

фронтон – соңгы этажның тәрәзәләренең өске ноктасыннан яки чыгып торган элементларыннан фасадның өске ноктасына кадәр үлчәнә торган түбә биеклегеннән чыга торган бина фасадының бетерү өлеше;

төзекләндерү элементлары – төзекләндерүнең җыелма өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, үсемлек компонентлары, җиһазлауның һәм бизәүнең төрле төрләре, кече архитектура формалары, капиталь һәм стационар булмаган корылмалар, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләр.

## II. Территорияне төзекләндерүгә, карап тотуны һәм җыештыруны оештыруга гомуми таләпләр

7. Торак пунктның бөтен территориясе (торак йортларны да кертеп) һәм корылмалар (ары биналар, корылмалар) төзекләндерелергә, карап торылырга һәм җыештырылырга тиеш.

8. Гомуми кулланылыштагы территорияләрне, шул исәптән урамнар, үтү юллары, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, яр буйлары, скверлар, пляжлар, башка объектлар белән каплап алынган җир участокларын  карап торуны һәм җыештыруны үз вәкаләтләре чикләрендә вәкаләтле органнар гамәлгә ашыра.

9. Физик һәм юридик затлар үзләренең оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә милек хокукында, башка әйбер яки мәҗбүри хокукта үз карамагында булган җир участокларын (ары – җир участокларының хокуклы ияләре), шулай ук гамәлдәге законнар һәм әлеге Кагыйдәләр билгеләгән күләмдә биналар һәм корылмаларын, мөстәкыйль рәвештә яки үз акчалары хисабына специальләшкән оешмаларны җәлеп итеп карап тотуны һәм җыештыруны гамәлгә ашыралар .

Әгәр бина, корылма милек хокукында яки башка мәҗбүри хокукта берничә затка караган очракта, җыештырылырга тиешле территория милек хокукына яки башка күчемсез милек хокукына пропорциональ өлешләрдә билгеләнә.

Әгәр җир участогы территориясендә төрле затка караган берничә бина, корылма булган очракта, территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре якларның килешүе белән билгеләнә.

Килешү булмаган очракта җыештырылырга тиешле территория биналарның, корылмаларның бөтен милекчеләре яки башка хуҗалары (файдаланучылар) арасында тигез өлешләргә бүленеп билгеләнә.

Әгәр физик яки юридик зат карамагындагы җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, җир участогының биләмәдә булган фактик оешкан чикләрендәге территория җыештырылырга тиеш .

Бина, корылма милек хокукында яки башка әйбер я мәҗбүри хокукта беричә затка караган очракта, фасадны карап тору якларның килешүе белән билгеләнә ала.

Килешү булмаганда фасадны карап тоту милек хокукыны яки күчемсез милек объектына башка хокукка пропорциональ өлештә гамәлгә ашырыла .

10. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын, тротуарларны карап тоту һәм җыештыруны тәэмин итүчене (подрядчик, башкаручы) билгеләү буенча үткәрелгән эш нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрү өчен муниципаль контракт төзегән специальләшкән оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен карап тору һәм җыештыру күпфатирлы йортлар белән идарә итүнең бер ысулы нигезендә гамәлгә ашырыла:, - тарафыннан күпфатирлы йорт белән әлеге йорттагы милекчеләре турыдан-туры идарә иткәндә (ары – идарә итүче оешмалар) торак милекчеләренең ширкәте яисә торак кооперативы яки башка специальләшкән кулланучылар ширкәте, идарә итүче оешма, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен үтәүче затлар тарафыннан.

12. Шәхси торак йортларның территориясен карап тотуны һәм җыештыруны мондый йортларның милекчеләре (наемлаучылар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Яшелләндерү элементларын карап тоту һәм төзекләндерүне түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

1) китерелгән җир участогы чикләрендә – җир участогының милекчеләре яки башка төр хокук ияләре;

2) гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә – вәкаләтле орган яки тәэмин итүче (подрядчик, башкаручы) билгеләгән нәтиҗәләр буенча мондый эшләрне үтәүгә муниципаль контракт төзегән оешма;

3) кулланылышы чикләнгән (предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр) һәм махсус билгеләнгән (санитар зоналар, сусаклау зоналары, зиратлар, питомниклар) яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә – әлеге объектларның ияләре;

4) йорт яны территорияләре чикләрендә – күпфатирлы йортлардагы урыннарның ияләре яки идарә итүче оешмалар;

5) җир өсте коммуникацияләренең саклаулы зоналарында, шул исәптән элетрик челтәрләр, яктырту челтәрләре, радио линияләре – күрсәтелгән коммуникацияләрнең ияләре;

6) җир асты коммуникацияләренең саклаулы зоналарында (урнаштыру рөхсәт ителсә) – күрсәтелгән коммуникацияләрнең ияләре.

14.Урамнардан һәм юллардан грунт һәм өслек суларын агызу өчен каралган кюветларны, трубаларны, дренаж корылмаларын җыештыру һәм чистарту, яңгыр канализациясе коллекторларын һәм яңгыр суларын җыючы коеларны чистарту аларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

15. Җәмәгать бәдрәфләрен урнаштыру һәм карап тоту тәртибе гамәлдәге законнар, санитар кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә билгеләнә.

Бәдрәфләрнең санитар һәм техник хәле өчен аларның милекчеләре, ияләре, арендага алучылары, яки аларны хезмәт күрсәтүгә алган специальләшкән оешмалар җаваплылыкта.

16. Төзекләндерү эшләрен башкару вакытлары объектларның санитар һәм техник хәленә тиешле тәэмин ителешен исәпкә алып, эшләрнең заказчигы тарафыннан билгеләнә .

17. Торак пунктларның карап тоту һәм җыештыру чикләре физик һәм юридик затлар тарафыннан тапшырылган җир участоклары чикләре нигезендә билгеләнә (җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта биләүдә каралган җир участогының фактик барлыкка килгән чикләрендә).

18. Вәкаләтле орган үзенең вәкаләтләре чикләрендә торак пункт территориясен, шулай исәптән гомуми файдаланууда булган территорияләрне карап тору һәм җыештыру буенча эшләрнең үтәлүенә контрольне гамәлгә ашыра.

## III. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын карап тотуга, фасадларның һәм коймаларның, юлларның, шәхси торак йортларның, яңгыр канализацияләре челтәрләрен, яңгыр һәм күзәтү коеларын, су агызу корылмаларын, техник элемтә чараларын, тышкы яктырту объектларын, кече архитектура формаларын, стационар булмаган объектларны, төзелеш эшләре җитештерү урыннарын, күмү урыннарын, автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклап тору урыннарын карап торуга таләпләр. Торак пункт территориясенең бәйрәмчә бизәлеше

### Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын карап тору буенча гомуми таләпләр

19. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын карап торуны аларның милекчеләре яки башка хокук ияләре мөстәкыйль рәвештә яки үз акчалары хисабына специальләшкән оешмаларны җәлеп итеп гамәлгә ашыралар.

20. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир участогын карап тоту биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир участокларын төзекләндерүне үз эченә ала:

- биналарның, корылмаларның фасадларын карап тотуны;
- җир участогын җыештыруны һәм санитар-гигиеник чистартуны;
-гражданнарның, оешмаларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю һәм чыгару;
- җир участогында урнашкан яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын карап тоту .

21. Биналар һәм корылмаларның фасадларының төзелеш өлешендә, декоратив бизәлешендә һәм инженер элементларында күзгә күренеп торган кимчелекләре булмаска тиеш һәм эстетик хәле тиешле дәрәҗәдә сакланырга тиеш. Бинаның фасадында буяу кубулар фасадның гомуми мәйданының 1% ыннан артык булмаска тиеш.

### Биналарның, корылмаларның фасадларын карап тоту

22. Биналарның, корылмаларның фасадларын карап тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-конструкция элементларын һәм фасадны бизәкләүгә вакытында ярдәмче ремонт ясау һәм кабат торгызу, шул исәптән керү ишекләрен, балкон һәм лоджия киртәләрен, кәрнизләрне, ишек башларын, баскыч алларын һәм аерым баскычларны, баскычларның һәм төшү юлларының киртәләрен, витриналарны, декоратив детальләрне һәм башка конструкция элементларын торгызу һәм аларны буяу, бизәү;
-суүткәргеч җайланмаларның, торбаларның үз урынында һәм төзек хәлдә булуын тәэмин итү;
-җөйләрне, ярыкларны һәм тишелгән урыннарны герметик сылау һәм төзәтелгән булуы;
-фасад өслекләрен, шул исәптән фасад элементларын, аларның торышы һәм эксплуатацияләү шартларыннан чыгып, вакытында чистарту һәм юдыру;
-тәрәзәләрне һәм витриналарны, язмаларны һәм күрсәткечләрне вакытында юу;
-язулардан, рәсемнәрдән, белдерүләрдән, плакатлардан һәм башка мәгълүмат-басма продукциядән, шулай ук төшерелгән граффитилардан чистарту .

23. Биналарның, корылмаларның, торак булмаган янкорма урыннарның милекчеләре, башка хокук ияләре һәм тиешле вазыйфалар йөкләнгән башка затлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш :

-кирәк булганда, ләкин елга бер тапкырдан ким түгел, фасадларны чистартырга һәм юарга;

-кирәк булганда, ләкин елга ике тапкырдан да ким түгел, язын (җылыту системасын өзгәннән соң) һәм көзен (җылыту сезоны башланганчы) химик чаралар кулланып эчке һәм тышкы тәрәзә пыялалары өслекләрен, балкон һәм лоджия ишекләрен, подъездларда керү ишекләрен чистартырга һәм юарга;

-фасадның фактик халәтен исәпкә алып 5-6 елга бер мәртәбә, шул исәптән фасадны буяуны да кертеп агымдагы ремонт ясарга;

-фасадның аерым элементларына (цокольләргә, баскыч алларына, баскычларга, керү ишекләренә, ишек өсләренә, цоколь тәрәзәләренә, линияле ачылуларга һәм башка конструкция элементларына) агымдагы ремонт ясарга;

- (киртәләр, челтәрләр урнаштыру, элементның җимерелеп баручы кисәкләрен сүтеп алу һәм ш.б.) чыгып торган фасад конструкцияләренең җимерелү куркынычы булган очракта саклану-кисәтү чаралары күрергә;

- тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларын (вывесканы) мондый чаралар эксплуатацияләнмәгән очракта (арендатор (субарендатор) китүе һәм башка очраклар) сүтәргә.

24. Фасадларны экслуатацияләгәндә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- диварларның өслекләренә, фасадларның чыгып торган җирләренә, эргәләргә зыян китерү (пычрату): су аккан эзләр булу, буяу кубу, ярыклар булу, штукатурка яки тышлык кубу, салынган кирпечкә зыян килү, тимер-бетон конструкцияләрнең саклау катламы кубу һәм башкалар;

- панельләр кушылган урыннарда герметизация бозылу;

-биналарның яки корылмаларның штукатуркасына, тышлыгына, фасадларның цоколь өлешенең буяу катламына, шул исәптән тәрәзә конструкцияләренең, керү приямкаларының төзексезлеге;

-биналарның һәм корылмаларның фасадларының чыгып торган элементлары: балконнар, лоджияләр, эркерлар, тамбурлар, кәрнизләр, козыреклар һәм ш.б. зарарлануы;

-балконнар, лоджияләр, парапетларның җимерелүе (булмавы, пычрануы);

-фасадта һәм (яки) бина, корылма түбәсендә, учреждение такталарын, режим табличкаларын исәпләмәгәндә, вәкиллекле орган белән килешенгән паспорты булмаган тышкы мәгълүмат урнаштыру чараларын кую һәм эксплуатацияләү;

-белдерүләр, плакатлар һәм башка мәгълүмати-басма продукцияне биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасадларына, тәрәзәләренә (шул исәптән тәрәзәләрнең эчке ягына), пыялаланган ишекләргә (шул исәптән пыялаланган ишекләрнең эчке ягына) аларны алга таба файдалану өчен элү һәм ябыштыру;

-биналарның, корылмаларның фасадларына бу биналарның, корылмаларның милекчеләре, күпфатирлы йортта фатир милекчеләренең рөхсәтеннән башка граффити төшерү.

25.Рөхсәт ителә:

-подъездларга керү юлында мәгълүмат стендлары куярга;

-проект чишелеше нигезендә биналар түбәсендә эфир телевидениесен коллектив кабул итү системасы кабельләрен урнаштырырга.

**Күрсәткечләр**

26. Биналарның, корылмаларның фасадлары күрсәткечләр, билгеләр белән җиһазланырга тиеш.

27. Территорияләрнең тарихи чикләрендәге биналарда, корылмаларда, шулай ук авыл мохите эстетикасының югары таләпләрен сорый торган фасадлары белән урамга һәм юлга чыккан биналарда урнашкан күрсәткечләрдәге урам исемнәре һәм йорт номерлары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә

күрсәтелә. Күрсәткечләр һәм номер билгеләре чиста һәм төзек хәлдә карап тотылырга тиеш. Күрсәткечләр һәм номер билгеләренең чисталыгы һәм төзеклеге өчен биналарны карап тоту өчен җаваплы затлар җаваплылык тота.

**Керү юллары (төеннәр)**

28. Бина, корылмаларның керү юлларын яктырту җиһазлары, ишек башлары (козырек), өслекләр бәйләнеше элементлары белән (баскычлар һәм б.ш.) инвалидлар һәм халыкның азмобильле төркеме хәрәкәте өчен (пандуслар, тоткычлар һәм башкалар) белән җиһазларга кирәк.

Пандус тайдырмый торган материалдан эшләнгән, кытыршы өслекле, горизонталь уемнарсыз булырга тиеш. Пандуслар янында койма рәвешендәге киртәләр булмаган очракта биеклеге 75 миллиметрдан ким булмаган бортиклар һәм тотыну җайланмалары куяю күздә тотыла. Бордюр пандусының авышлыгы 1:12 булганда кабул ителә.

Пандус борылган очракта яки аның озынлыгы 9 м артса, 9 м саен 1,5х1,5 м размерлы горизонталь мәйданчыклар кую киңәш ителә. Горизонталь мәйданчыкларда төшү ахырында дренаж җайланмалары проектларга кирәк. Пандусларның башында һәм ахырында булган горизонталь участокларны якындагы өслекләрдән текстурасы һәм төсе белән аерылып торырлык итеп ясарга кирәк.

Баскычларның һәм пандусларның ике ягында да 800-920 мм биеклектәге, стенадан 40 мм ераклыкта урнашкан түгәрәк яки турыпочмаклы тотынгыч җайланмалар кую карала. Баскычлар 2,5 метрдан киңрәк булган очракта уртада аерып торучы тотынгыч җайланмалар кую күздә тотыла. Тотынгыч җайланмаларның озынлыгы, ике яктан да, 0,3 метрга озынрак итеп урнаштырыла. Тотынгыч җайланмаларның конструкциясе кул белән тимергә тотынмаслык итеп эшләнелергә тиеш.

29. Керү юлларын проектлаштырганда, биналарның, корылмаларның фасадын яңартканда, үзгәрткәндә рөхсәт ителми:

-идән биеклеге фасадтагы җир өслегеннән 1,2 м биегрәк урнашкан очракта, гомуми кулланылыштагы территориягә чыга торган подвал һәм цоколь этажына, урыннарга чыгу юллары урнаштырырга;

-җәяүлеләрнең хәрәкәтенә комачаулык тудыра торган терәткеч элементлар (колонналар, баганалар) кую;

- проект документациясенең бинаның бөтен фасады комплекслы чишелешен искә алып башкарылган эшләнмәсеннән башка ике яки күбрәк (булганнарын исәпкә алып) керү юлы куярга;

- тротуарларының норматив киңлеге минималь булган урам юллары челтәрләренең тротуарлы зоналарында җиңел конструкцияле керү юллары элементларын (баскычлар, пандуслар, ишек төпләре, яшелләндерү) тоташучы тротуарларга 0,5 м дан да якын ясау;

-күпфатирлы йортларга керү юлларын торак йорттагы фатирларның милекчеләре рөхсәтеннән башка урнаштыру;

-торак урынның милекчесе рөхсәтеннән башка балконнарны керү юллары урнаштыру өчен куллану;

-вәкәләтле орган килешенүеннән башка күпфатирлы йортларның торак булмаган урыннарына үз белдеге белән керү юллары урнаштыру.

**Түбәләр**

30.Биналарның, корылмаларның түбәләре, су агызу системасы элементлары, төтенчыккычларның һәм вентиляция системаларының башлары төзек хәлдә тотылырга тиеш һәм нинди һава торышы шартлары булуга карамастан торак йортта яшәүчеләргә куркыныч китермәскә тиеш .

31. Кыш айларында биналарның хуҗалары һәм башка хокукый затлар, шулай ук күпфатирлы йортлар каршында оештырылган идарәче оешмалар тарафыннан түбәләрне

кардан, бозланулардан, боз сөңгеләреннән вакытында чистарту эшләре оештырылырга тиеш. Түбәләрне кардан чистарту эше җәяүлеләр йөри торган якта башкарылса, махсус киртәләр куеп, барлык саклану чараларын күреп, көннең якты вакытында гына башкарылырга тиеш.Түбәнең калган авышлыкларыннан, шулай ук яссы түбә өслегеннән кар эчке ишегалдына төшерелергә тиеш. Җәяүлеләр һәм машиналар йөри торган юлларга, җәмәгать транспортын көтү тукталышларына түбәдән төшерелгән кар һәм бозлар тиз арада чистартып алынырга тиеш.

32. Түбәләрдән кар һәм боз төшерелгәндә, боз сөңгеләреннән чистарту эшләре вакытында агач һәм куакларны, электр чыбыкларының һава линиясен, яктылык һәм телефон чыбыкларын, юл билгеләрен, юл буендагы светофорларны, киртәләрне, юл күрсәтүче җайланмаларын, җәмәгать транспортын көтү павильоннарын, декоратив бизәкләү һәм инженер элементларын саклау өчен барлык шартлар да тудырылырга тиеш. Алда күрсәтелгән элементларга зыян китерелгән очракта, алар түбәләрне чистартучылар һәм зыян салучы затлар тарафыннан үз акчаларына, яңадан торгызыла.

33. Бина һәм корылмаларның түбәләре, җәяүлеләр һәм җәяүлеләр йөри торган юлларга түбәдән су акмаслык итеп, су агу юллары белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Улаклар, воронкалар һәм су агу торбалары үзара тыгыз тоташтырылган һәм җыелган су агымын үткәрелерлек булырга тиеш. Җәяүлеләр йөри торган юллар ягына чыгучы су агу торбалары җәяүлеләр йөри торган юлның ары чыгарылырга тиеш.

34. Рөхсәт ителми:

-биналарның, корылмаларның түбәләрендә түбәләрне эксплуатацияләүдә кулланыла торган предметлар (көрәкләр, кыргычлар, ломнар), төзелеш материаллары, ремонт калдыклары, куланылмый торган механизмнар һәм башка предметлар сакларга;

-су агызу торбалары воронкаларына бина түбәсеннән кар, боз һәм чүп ташларга.

**Җир участокларын карап тоту**

35. Җир участокларын, карап тору үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-чүптән, яфраклардан, кар һәм боздан (бозланудан) көндәлек җыештыру;

-машиналар йөри торган юлларны, күперләрне, урамнарны, тротуарларны, тыкрыкларны, җәяүлеләр йөри торган урыннарның өслекләрен бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү;

-карны көрәү һәм себерү;

-карны, бозны (бозлы кар катламнарын) түгү;

-контейнер өчен мәйданчыкларны, төрле калдыклар өчен билгеләнгән контейнерларны чүп савытларын, эскәмияләрне, кече архитектура формаларын һәм башкаларны кую, чиста һәм техник яктан төзек хәлдә тоту ;

-чүп кабул итү камераларын, контейнерларны (бункерларны) һәм контейнер мәйданчыкларын җыештыру, юу, һәм дезинфекцияләү;

-яңгыр һәм кар суларын агызу;

-каты көнкүреш, эре габаритлы һәм башка калдыкларны җыю һәм чыгару;

-һаваны тузаннан арындыру һәм дымландыру өчен территориядә су сиптерү;

-утыртылган яшел үсентеләрне саклау һәм карап тоту;

- коммуналь хезмәт күрсәтүче объектларын, инженер коммуникацияләрен (корылмаларны), тимер юллар, юллар, күперләр, җәяүлеләр өчен юл аша чыгу урыннарын төзегәннән, реконструкцияләгәннән, төзекләндергәннән һәм башка төрле казу эшләре алып барганнан соң бозылган төзекләндерү элементларын торгызу, реставрация, археология һәм башка казу эшләре алып бару;

-күзәтү һәм яңгыр суларын җыю коеларын (яңгыр канализацияләре), җир асты коммуникацияләре киртәләрен (корылмаларын) гамәлдәге дәүләт стандартлары нигезендә карап тоту;

-җир участоклары киртәләрен, шул исәптән җимерелгән (сүтелгән; сүтелүче) биналар, корылмаларны, алар территориясенә чит затлар үтеп керү мөмкинлеген һәм (яисә) рөхсәт ителмәгән урыннарга калдыклар кую мөмкинлеген булдырмый торган коймалар кую һәм аларны карап тоту, шулай ук аларны пычрактан, кардан һәм мәгълүмати-басма продукциясеннән вакытында чистартуны тәэмин итү.

## Юлларны карап тоту

36. Юлларны карап тотуны мондый эшләрне үтәүгә тәэмин итүчене (подрядчик, башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча сайлап алынган муниципаль контрактлар төзегән оешмалар гамәлгә ашыра.

37. Юл территорияләрен карап тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге юлларны ремонтлау;

-тротуарларны (җәяүлеләр зоналарыннан, сукмаклардан) һәм юлның автомобильләр йөри торган өлешен, ясалма юл корылмаларын пычрактан, чүптән, кардан һәм боздан (бозлавык) чистарту;

-юл өслекләрен юу һәм су сиптерү;

-газоннарны һәм яшел үсентеләрне карап тору;

-тышкы яктырту һәм җәмәгать һәм тимер юл транспортының контакт челтәре баганаларын ремонтлау ;

-кече архитектура формаларын ремонтлау һәм буяу;

- күзәтү һәм яңгыр сулары агып китә торган коеларны ясау, төзекләндерү һәм чистартып тору;

- коймаларны, рәшәткәләрне, турникетларны, кече архитектура формаларын кую, төзекләндерү һәм ел саен буяу;

38.Юл өслекләрен саклау максатында рөхсәт ителми:

-йөкне өстерәтеп алып килү;

-төяү-бушату эшләре вакытында урамнарга рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, торбалар, кирпеч, башка авыр предметларны ташларга һәм аларны анда сакларга;

- автомобильләр йөрү юлларына һәм тротуарларына төзелеш материалларын һәм төзелеш калдыкларын ташларга һәм (яки) сакларга.

39. Юлларны төзекләндерүнең аерым элементларына таләпләр:

-җәяүле юллары коймаларының металл юнәлдергечләре һәм тротуар баганаларын сезонлы буяу ел саен кышкы сезон тәмамланганнан соң төзекләндерү айлыгын үткәргән вакытта башкарыла. Буяу алдыннан коймалар ремонтланырга, пычрактан чистартылырга, юылырга һәм грунтовкаланырга тиеш;

-бөтен юл разметкасы, аларны ясауга расланган паспорт (схема) нигезендә, эшләргә заказ бирүче билгеләгән срокларда һәм чират тәртибендә башкарылыррга тиеш;

-юлларга юл билгеләре төшерү таләп ителгән төс һәм яктылык техник сыйфатламаларын, тоташтыру коэффициенты, эксплуатация ителүнең бөтен вакытында мәйданы буенча саклануы тәэмин итәргә тиеш;

-юл билгеләренең конструкциясе һәм беркетү системасы күрү шартларына һәм монтажлау мөмкинлекләренә бәйле;

-юл билгеләре төзек хәлдә карап торылырга, вакытында чистартылырга һәм юылырга тиеш.

Вакытлы куелган юл билгеләре аларны куярга мәҗбүр иткән сәбәпләр бетерелгәннән соң бер тәүлек эчендә алынырга тиеш;

-визуаль-коммуникация системасы элементлары: транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте юнәлешләре күрсәткечләре, торак пунктның планировка-структура элементлары күрсәткечләре юлларда һәм транспорт чишелешләрендә аларга таба хәрәкәтне күрсәтү өчен куелалар;

**Шәхси торак йортларны карап тоту һәм территорияне төзекләндерү**

40. Шәхси торак йортларның милекчеләре (яки) яллаучылары (ары - торак йортларның ияләре), закон яки килешү белән башкалар затлар каралмаса түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар:

-торак йортның фасадларының, киртәләрен (коймаларын), шулай ук йорт биләмәләре чикләрендәге башка корылмаларны тиешле хәлдә саклауны, аларны вакытында ремонтлау һәм буяу;

-торак йортка номер билгесен тиешенчә беркетү;

-йорт биләмәсен тәртиптә тоту һәм тиешле санитар хәлендә карап тотуны тәэмин итү;

-йорт биләмәләре чигендә яшел утыртмаларны тәртиптә тоту, агач һәм куакларны санитар кисү үткәрү, газүткәргеч, электр тапшыруның кабельле һәм һава линияләре һәм башка инженер челтәрләренең саклаулы зоналарында агач утыртуга юл куймау;

-су агу өчен канауларны һәм торбаларны чистарту, язгы вакытта кар суларының агып китүен тәэмин итү;

-бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә үзәкләштерелгән канализация булмаса, санитар нормалар нигезендә үз канализацияләрен, чүп базын, бәдрәф урнаштыралар, аларны даими рәвештә чистарталар һәм дезинфекциялиләр;

-каты һәм эре габаритлы калдыкларны махсус мәйданчыкларга куелган контейнерларга туплау ;

-билгеләнгән тәртип нигезендә каты көнкүреш һәм эре габаритлы калдыкларны вакытында җыюны һәм чыгаруны тәэмин итәләр.

41.Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:

-йорт биләмәләрен һәм алар янәшәсендәге территорияләрне "чүп үләннәре белән чүпләндерү", яфракларны, теләсә нинди калдыкларны, чүп-чарны яндыру;

-“йорт тирәсе” территориясен теләсә нинди калдыклар белән чүпләү;

-йорт биләмәләре чикләреннән ары коймалар урнаштыру;

- йорт биләмәләре һәм аңа тоташа торган территорияләрдә яфракларны, теләсә нинди калдыкларны, чүп-чарны яндыру;

-күмер, тара, утын, эре габаритлы калдыкларны йорт биләмәсе территориясеннән читтә урнаштыру;

-йорт биләмәсеннән читтә ишегалды корылмалары төзү, чүп базлары урнаштыру ;

- әлеге территориянең машиналар йөри торган өлешләрендә махсус транспорт һәм җыештыручы техниканың үтеп йөрүен кыенлаштыра торган киртәләр урнаштыру;

-территорияне төзекләндерү элементларын бозу һәм җимерү, сулыкларны чүпләү;

-йорт биләмәләреннән читтә сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чараларын саклау;

-якын-тирә территорияне теләсә нинди калдыклар белән чүпләү;

-автомобиль йөрү юлларына юынтык сулар салу җайланмалары урнаштыру, сыек пычракларны агызу, җитештерү һәм куллану калдыкларын чыгару.

Җир участогы хуҗасы тарафыннан хуҗалык корылмалары төзү гамәлгә ашырылганда, якын-тирә территориядә төзелеш материаллары сакларга (6 айга кадәр) рөхсәт ителә. Бу очракта автотранспорт үтеп йөрүе тәэмин ителергә тиеш.

**Яңгыр канализацияләрен, күзәтү һәм яңгыр коеларын, су агызу корылмаларын карап тоту**

42. Күзәтү һәм яңгыр җыю коелары, җир асты коммуникацияләре, люклар (рәшәткәләр) ябык килеш торырга тиеш һәм транспорт һәм җәяүлеләрнең куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итә торган төзек хәлдә сакланырга тиеш.

43. Кабул итү, тупик, күзәтү һәм башка коеларны һәм камераларны карап тоту, чистарту һәм төзек техник хәлдә тотуны гамәлдәге дәүләт стандартлары таләпләре нигезендә аларның хуҗалары тәэмин итә.

44. Торак пунктта магистраль һәм эчке квартал яңгыр канализациясе челтәрләрен карап тоту һәм эксплуатацияләү торак пункт бюджетында бу максатларга каралган чаралар чигендә специальләшкән оешмалар белән төзелгән килешүләр нигезендә башкарыла .

Яңгыр канализациясенең ведомство челтәрләрен эксплуатацияләү тиешле оешмалар чаралары исәбенә башкарыла.

Хуҗасыз инженер коммуникацияләре һәм күзәтү коелары тиешле куркынычсыз хәлдә юлларны карап тотуны гамәлгә ашыручы специальләшкән оешмалар тарафыннан башкарылырга тиеш.

45. Яңгыр канализациясенең коллекторлары саклау өчен коллектор үзәгеннән һәр якка 2 м сак зонасы урнаштырыла.

46. Яңгыр канализациясе коллекторлары зонасында тиешле документлар төземичә һәм язмача килешенүдән башка, эксплуатацияләүче оешмалар, башка органнар белән гамәлдәге законнар билгеләгән очракларда рөхсәт ителми:

-җир эшләре башкару;

-яңгыр канализациясе челтәрләрен зарарларга, су кабул итү люкларын ватарга һәм җимерергә;

-төзелеш алып барырга, сәүдә, хуҗалык һәм көнкүреш корылмалары урнаштырырга;

-сәнәгый, көнкүреш калдыклары, чүп һәм башка материаллар ташларга.

47. Суүткәргечләрнең, канализация, яңгыр җайланмаларының, системаларның, челтәрләрне һәм корылмаларның төзексезлеге аркасында су агып, урамнарны, биналарны, корылмаларны су басарга тиеш түгел.

48. Торак пункт территориясендә йоту коелары һәм пар киптергеч җайланмалар рөхсәт ителми.

49. Яңгыр кабул итү коеларының рәшәткәләре һәрвакыт чистартылган хәлдә булырга тиеш. Коеларның һәм рәшәткәләрнең үткәрүчәнлеген чикли торган чүпләнү, тыгылулар булырга тиеш түгел. Күзәтү һәм яңгыр канализациясенең яңгыр кабул итү коеларының профилактик тикшерү һәм аларны чистарту елга ике тапкырдан да ким булмаска тиеш. Күзәтү һәм яңгыр кабул итү коеларыннан чыгарылган чүп-чар шунда ук чыгарылырга тиеш.

50. Күзәтү коеларының люклары автомобиль йөрү юллары, тротуарлар, җәяүле һәм велосипед юллары, яшел зоналар капламы өслеге белән бер тигезлектә булырга тиеш.

Күзәтү коеларының люклары автомобиль йөрү юллары, тротуарлар, җәяүле һәм велосипед юллары, яшел зоналар капламы өслеге тигезлегеннән 2 см га тайпылу рөхсәт ителә, яңгыр кабул итү коеларына – 3 см дан артык түгел.

51. Капкачлары һәм рәшәткәләре җимерелгән яки бөтенләй булмавы билгеле булу белән, коммуникация коелары челтәрләрне эксплуатацияләүче оешма тарафыннан киртәләп аланырга, тиешле кисәтү билгеләре куелырга һәм билгеләнгән срокларда алыштырылырга тиеш.

52. Инженер челтәрләрендә планлы эшләр вакытында канализация агынтылары якындагы канализация челтәре коеларына түгелә, суүткәргеч һәм җылылык челтәре суларын - яңгыр канализациясенә (булганда). Суларны юлга агызу тыела.

Су агу нәтиҗәләрен бетерү зарарланган инженер челтәрләренең көчләре белән һәм аларның чаралары хисабына үтәлә.

53. яңгыр канализациясе челтәрләренең төзек техник торышы (шул исәптән люкларны һәм рәшәткәләрнең вакытында бикләнүе өчен) җаваплылык эксплуатацияләүче оешмаларга йөкләнә.

## Техник элемтә чараларын карап тору

54. Биналарны инженер-техник яктан тәэмин итүгә каралган элемтә челтәрләре, телевидение, радио, Интернет һәм башка шуңа охшаш челтәрләрнең чыбыклары җир асты (траншея, каналлар, тоннельләр) буйлап кертелә.

55. Биналарга тышкы коммуникацияләрне башка юллар (һава буйлап, җир өстеннән) кертү, җир астыннан кертү мөмкинлеге булмаганда, эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан тиешле техник шартлар тудырылганда гына рөхсәт ителә.

56. Элемтәнең элмә линияләрен һәм кабельле һава күчергечләрен беркетү сыйфатында түбәндәгеләрне кулланырга ярамый:

-автомобиль юлларын төзекләндерү элементлары: юл киртәләре, светофор һәм юл билгеләре кую өчен билгеләнгән конструкцияләр һәм элементлар;

-фасад, түбә, бина һәм корылма стеналарының (төтенчыккычлар, вентиляция, телевидение һәм радионы коллектив кабул итү системалары антенналары, фронтоннар, козыреклар, ишекләр, тәрәзәләр) элементларын;

57. Рөхсәт ителми:

-элемтә кабельләрен һава юлы белән бер бинадан икенчесенә сузганда юлларны аркылы үтәргә;

-кабель запасларын билгеләүче муфта тартмасыннан тыш урнаштырырга;

58. Милекчеләр (хуҗалар) техник элемтә чараларын (кабельләрне, кабельләрне ныгыту элементларын, бүлеп таратучы һәм муфталы тартмалар һәм башкалар), шулай ук алар ярдәмендә тоташтырыла торган техник җайланмаларны тиешле хәлдә (өзеклекләр һәм/яки изоляция тышлыгы булмавы, буяусыз, коррозия булуы һәм/яки механик бозылулар, чыбыкларның асылынуын һәм/яки аларның яктырту һәм электр линиясе баганаларына чорналуын булдырмыйча) карап тотарга тиеш.

## Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тору

59.Тышкы яктырту элементларына яктырткычлар, кронштейннар, баганалар, үткәргечләр, кабельләр, тукландыру чыганаклары (шул исәптән җыю, тукландыру пунктлары, идарә тартмалары).

60. Урамнар, юллар, җәяүлеләр йөри торган тротуарлар, торак кварталлар, ишегаллары, предприятие, учреждение, оешма территорияләре, шулай ук җәмәгать һәм торак йортларның аншлаглары һәм номер билгеләре, юл билгеләре һәм күрсәткечләр, җирлек мәгълүмат элементлары һәм витриналар тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.

61. Биналарның һәм корылмаларның милекчеләре милек формасына бәйсез рәвештә проектлар буенча биналарның һәм корылмаларның архитектур-сәнгати яктыртылышын булуын һәм эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

62. Эшләмәүче яктырткычларның саны төп мәйданнарда, магистраль һәм урамнарда, транспорт тоннельләрендә 3% тан артырга тиеш түгел, башка торак пункт территорияләрендә (район әһәмиятендәге урамнарда, ишегалды территорияләрендә) – 5%, җир асты җәяүле чыгуларда көндезге , шулай ук кичке һәм төнге режимнарда – 10% (10 тоташтырылган яктырткычка 1 тоташтырылмаган рөхсәт ителә).

63. Гамәлдән чыккан, составында терекөмеш булган лампалар махсус шул максат өчен билгеләнгән бүлмәләрдә сакланырга һәм аларны утильләштерүче предприятияләргә озатылрга тиеш. Алда күрсәтелгән лампаларны чүплекләргә яки чүп эшкәртүче заводларга озатылырга тиеш түгел.

64. Тышкы яктырту җайланмаларының тимер баганалары, кронштейннары

һәм башка элементлары чиста халәттә тотылырга, кәкрәйгән булмаска, күгәрексез булырга һәм милек хуҗалары тарафыннан (хуҗалар, кулланучылар) кирәк булган саен, ләкин өч елга бер тапкырдан да кимрәк булмыйча, буялырга, карап тотылырга тиеш.

65. Урамдагы, йортлар янындагы яктырту җайланмаларын карап тору, ремонтлау һәм бердәм тышкы яктырту системасына тоташтыру эшләрен, муниципаль сатып алу нәтиҗәләрен урнаштырган, әлеге эшләрне эшләргә рөхсәт алу максатыннан үткәрелгән, бәйгедә җиңгән вәкаләтле орган яки специальләшкән оешма тарафыннан алып барыла.

Торак йортларның тапшыру бүлгечләренә тоташтырган йорт яны утларын карап тоту һәм ремонтлау идарәче оешмалар тарафыннан башкарыла.

66. Тышкы яктырту баганалары, җәмәгать (тимер юл) транспорты контакт челтәре баганалары, саклагыч, аеру коймалары, юл корылмалары һәм юл җиһазлары элементлары буялырга, язулардан, теләсә нинди мәгълүмати-басма продукциядән арындырылырга, төзек һәм чиста хәлдә тотылырга тиеш тиеш.

67. Тышкы яктырту баганаларын, җәмәгать (тимер юл) транспортының контактлы челтәре баганаларын алыштырганда, күрсәтелгән конструкцияләр аларның хуҗалары тарафыннан өч тәүлек агымында сүтелергә һәм чыгарылырга тиеш.

Юллардагы бәреп аударылган тышкы яктырту баганаларын чыгару аларның хуҗалары тарафыннан кичекмәстән башкарыла, калган территорияләрдә – мондый зарурлык (сүтү) билгеле булу белән бер тәүлек эчендә.

68. Тышкы яктырту баганаларына һәм җәмәгать (тимер юл) транспортының контактлы челтәре баганаларына беркетелгән элемент һәм объектларның төзек һәм куркынычсыз хәле һәм канәгатьләнерлек тышкы күренеше өчен бу баганаларның милекчеләре (хуҗа) җаваплылык тота.

69. Чыбыклар өзелгәндә, баганалар, изоляторлар зарарланганда тышкы яктырту җайланмаларын эксплуатацияләү рөхсәт ителми.

Тышкы яктырту җайланмалары эшендә барлыкка килгән, электр үткәргечләре өзелү яки терәк баганаларга зыян китерү белән бәйле бозылулар, билгеле булгач ук, кичекмәстән төзәтелергә тиеш.

70. Электр чыбыкларын, кабельләрне рөхсәтсез, үз белдегең белән, тышкы яктылык челтәрләренә һәм җайланмаларына тотоштыру рөхсәт ителми.

71. Тышкы яктырту объектлары яки тышкы яктырту чаралары белән җиһазландырылган объектларның милекчеләре (хуҗалары), шулай ук тышкы яктырту объектларына (чараларына) хезмәт күрсәтүче оешмалар түбәндәгеләргә бурычлы:

-урамнарны, юлларны тиешенчә яктыртуны, баганаларның һәм яктырткычларның, яктырту җайланмаларының сыйфатын күзәтеп торырга, бозылган яки зыян күргән очракта вакытында ремонт ясарга;

-билгеләнгән тәртип нигезендә яктырту утларын кабызуны һәм сүндерүне тәэмин итеп торырга;

-тышкы яктырту утларын кую, карап тоту, урнаштыру һәм эксплуатацияләү, шулай ук рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтәргә;

-тышкы яктырту фонарьларын үз вакытында алмаштырырга.

**Кече архитектура формаларын карап тоту**

72. Кече архитектура формаларына монументаль-декоратив бизәлеш элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү өчен кирәкле җайланмалар, су җайланмалары, муниципаль мебель, җирлек территориясендәге коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар керә.

73. Кече архитектура формаларын карап тору участокларының хокукый ияләре тарафыннан, файдалануга бирелгән территориядә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрендә - вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин итүчене (подрядчик, башкаручыны)

билгеләү буенча үткәрелгән эшләр нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен уздыруга муниципаль оешма белән килешү (контракт) нигезендә тәэмин ителә.

74. Кече архитектура формалары хуҗалары түбәндәгеләрне тәэмин итәргә бурычлы:

-кече архитектура формаларының чиста һәм төзек хәлдә булуын карап торырга;

- язгы чорда аларны иске буяулардан, күгәрекләрдән арындырырга, юдыртып яңартып буярга, шулай ук ватылган элементларын яңаларга алмаштырырга;
- кышкы чорда кече архитектура формаларын, шулай ук алар янына килү юлларын кардан, боздан һәм бозлавыклардан чистартырга;
- шома өслекле киртә куеп комлыклар урнаштырырга һәм андагы комны елга бер тапкырдан да сирәк булмыйча алмаштырырга;
- хуҗалык мәйданчыкларында һәм ял мәйданчыкларында урнаштырылган балалар һәм спорт җиһазларының конструкция элементлары ныклыгын, ышанычлылыгын һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килүен күзәтеп торырга;
- фонтаннар эшләгән чорда көн саен су өслеген чүптән чистартып торырга;

75. Рөхсәт ителми:

- кече архитектура формаларын төп билгеләнеше буенча кулланмау (балалар өчен ясалган уен мәйданчыкларында өлкәннәргә ял итү, спорт мәйданчыкларында керләр киптерү һәм башкалар.);
- теләсә нинда мәгълүмати-басма продукцияне кече архитектура формаларына элү һәм ябыштыру;
- кече архитектура формаларын һәм аларның конструктив элементларын вату яки аларга зыян китерү;
- фонтаннарда су коену.

**Стационар булмаган объектларны карап тору**

76. Стационар булмаган объектларны урнаштыру муниципаль хокук актында билгеләнгән тәртипләр буенча, мондый объектларны урнаштыру схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

77. Җир участогын арендалау килешүе срогы чыкканнан соң, стационар булмаган объект арендатор тарафыннан сүтеп алына, ә җир участогы бушатыла һәм беренчел халәткә китерелә.

78. Стационар булмаган объектларның хуҗалары булган юридик һәм физик затлар түбәндәгеләргә бурычлы:

-аларны төзәтү һәм буяу эшләрен башкарырга. Ремонт, проект документациясе белән билгеләнгән төсләр кулланылышын, гомуми тышкы торышын исәпкә алып башкарылырга тиеш;

-якын-тирә территориядә үскән яшел үсентеләрнең, газоннарның, бордюр ташларының, кече архитектура формаларының (алар булганда) сакланышын күзәтеп торырга, билгеләнгән территорияне әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләр нигезендә карап торырга;

-стационар булмаган объектлар янында чүп савытлары урнаштырырга, чүп савытларын көн дәвамында кирәк булган саен, әмма бер тапкырдан да ким булмыйча чистартырга, елга бер тапкырдан да ким булмыйча аларны буярга;

79. Рөхсәт ителми:

-стационар булмаган объектлар янына янкормалар, козыреклар, япма корылмалар һәм башка проект буенча каралмаган конструкцияләр төзү;

-стационар булмаган объектлар янына сәүдә-суыткыч җиһазлар урнаштырырга;

-стационар булмаган объектлар янында һәм аларның түбәләрендә тартмалар, товарлар, детальләр, башка төрле көнкүреш һәм җитештерү характерындагы

предметларны җыю, шулай ук стационар булмаган объектларны склад максатында файдалану;

-стационар булмаган объектлар арасында янгынга каршы булдырылган ачыклыкларны җиһазлар, калдыклар белән каплау;

**Төзелеш мәйданчыкларын карап тоту**

80. Төзелеш мәйданчыкларын карап тоту, ремонт, төзелеш һәм башка төрле эшләр тәмамланганнан соң төзекләндерү төзүчегә йөкләнә.

Төзелеп бетмәгән, төзелеш эшләре алып барылмый торган төзелеш объектлары төзелеш челтәрләре белән ябылган булырга тиеш.

81. Төзелеш, ремонт һәм башка шундый төр эшләр башланыр алдыннан һәм эшләр башкарылган чорда түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

-төзелеш мәйданчыгының бөтен периметры буенча Башкарма комитетның хокукый актлары таләпләренә туры китереп типовой коймалар урнаштырырга;

-төзелеш мәйданчыгы коймасының гомуми тотрыклылыгын, ныклыгын, ышанычлылыгын, эксплуатаөион куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;

-төзелеш мәйданчыгы коймаларының тиешле техник халәтен күзәтеп торырга, пычрактан, кардан, боздан, мәгълүмати-басма продукциядән һәм граффитидан вакытында чистартып торырга;

-төзелеш мәйданчыгы территориясенә кергән урында, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә җавап бирә торган, төзелеш объектының мәгълүмат щитын урнаштырырга һәм аны тиешле хәлдә тотарга;

-төзелеш мәйданы периметры буенча тышкы яктыртуны тәэмин итәргә ;

-төзелеш мәйданчыгына төзекләндерелгән керү юллары, эчке мәйдан юллары һәм чыгу юлында, автомобиль йөри торган урамнарга (юлларга) пычрак һәм чүп чыгаруны булдырмас өчен, транспорт чараларын чистарту яки көпчәкләрен юу пунктлары булдырырга;

-төзелеш мәйданчыгы территориясендә көнкүреш каты, эре габаритлы һәм төзелеш калдыкларын җыю өчен контейнерлар һәм (яки) бункерлар урнаштыруны тәэмин итәргә;

-төзелеш мәйданчыгы территориясеннән билгеләнгән тәртиптә көнкүреш каты, эре габаритлы һәм төзелеш калдыкларын, чыгаруны оештыруны тәэмин итәргә;

-төзелеш мәйданчыгы территориясеннән җыештырылган һәм төзелеш калдыкларыннан арындырылган карны билгеле тәртиптә килешенгән махсус урыннарга чыгаруны тәэмин итәргә;

-эшләр башкарылган вакытта эшләүче җир асты инженер коммуникацияләрен, тышкы яктырту челтәрләрен, яшел үсентеләрне һәм кече архитектура формаларын саклауны тәэмин итәргә.

82. Төзелеш материаллары, җиһазлары, автотранспорт һәм күчмә механизмнар, ярдәмче биналар, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең вакытлыча урнашу өчен көнкүреш вагоннары, төзелеш калдыкларының транспорт партияләрен вакытлыча саклау һәм җыю өчен билгеләнгән урыннар, төзелеш оешмасы проекты нигезендә, төзелеш мәйданнары чикләрендә урнаштырыла.

83. Рөхсәт ителми:

-торак зонасы янында, гражданнарның шәхси һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү белән бәйле коткару, авария-торгызу һәм башка кичектергесез эшләрне исәпкә алмыйча, тынычлыкны бозып алып барыла торган төзелеш, ремонт, төяү-бушату һәм башка эшләрне 23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр оештыру һәм үткәрү;

-Башкарма комитетның тиешле рөхсәтеннән (күрсәтмәсеннән) башка автомобиль юлларының һәм тротуарларның тараюы яки ябылуы барлыкка килү;

-чүп-чар яндыру һәм төзелеш җитештерүе калдыкларын утильләштерү.

## Күмү урыннарын карап тоту

84. Этик, санитар һәм экология таләпләре нигезендә тапшырылган күмү урыннарын карап тоту Федераль законнар һәм муниципаль хокук акты билгеләгән күмү урыннарын карап тоту кагыйдәләренә туры китереп гамәлгә ашырыла.

85. Күмү урыннарының санитар хәлен карап торуны тәэмин итүчене (подрядчикны, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә муниципаль контракт төзегән специальләшкән оешмалар гамәлгә ашыра.

86. Күмү урыннарын карап тотуга таләпләр:

-зиратларда җәмәгать бәдрәфләре чиста һәм төзек хәлдә булырга тиеш. Җәмәгать бәдрәфләрләре янындагы чүп савытларычистартылган булырга тиеш;

-зират территориясендәге калдыклар өчен контейнерлар һәм чүп савытлары чистартылган булырга тиеш. Калдыклар туплану күләменә карап, 3 көнгә бер тапкырдан да ким булмаганча чыгарылырга тиеш;

-ауган һәм авария хәлендәге агачларның булуы рөхсәт ителми. Авария хәлендәге агачлар табылган вакытыннан бер тәүлек дәвамында чыгарылырга тиешле;

-каралмаган каберләрнең яки шәхесләре билгеләнмәгән мәетләрнең каберләре пычрак һәм чүптән арындырылырга, калкулык һәм кабер ташы белән җиһазланырга тиеш.

87.Күмү урыннарын кышкы чорда карап тору үзенчәлекләре:

-зиратның үзәк юллары, килү юллары, тротуарлар киңәйтелергә һәм кардан чистартылырга тиеш. Бозлы катламнарсыз тигез кар ятмасы рөхсәт ителә;

-үзәк юллар, керү юллары, тротуарлар бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә тиеш. Автомобиль йөрү юллары һәм тротуарларны эшкәртү кар явып туктауга башланырга тиеш;

-беренче чиратта кар чыгаруны, үзәк һәм килү юлларыннан бозларны ватып, барлыкка килгән кар-боз өемнәрен чыгаруны оештырырга кирәк;

-бозлавыкка каршы материалларны күмү урыннарының җәяүлеләр зоналарында куллану, юлдан чистартыла торган тозлы кар һәм бозны каберләр, газоннар, куаклыклар өстенә өю рөхсәт ителми.

88. Күмү урыннарын җәйге вакытта карап тоту үзенчәлекләре:

-үзәк юллар, керү юллары, тротуарлар, каберлекләр аралары һәм күмү урыннарының гомуми кулланылыштагы башка территорияләре төрле пычрануылардан арындырылырга тиеш;

-агачларны санитар кисү, агач-куаклыкларның чүп үсентеләреннән чистарту чаралары ел саен үткәрелергә тиеш.

89. Күмү урынын, кабер өсте корылмаларын (тәреләр, һәйкәлләр, плиталар,склеплар һ.б.), карап тору, чәчәк һәм декоратив куаклыклар утырту, колумбарийдагы нишаларны карап тору эшләре үлгәннәрнең хатыны (ире), туганнары, законлы вәкилләре яки башка затлар тарафыннан санитар таләпләрне мәҗбүри үтәп гамәлгә ашырыла.

## Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска срокка саклауга кую урыннарын карап тору

90. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска срокка саклауга кую урыннарын (ары - автокую) карап тору автокуюны урнаштыру өчен бирелгән җир участогының хокук иясе (ары – хуҗа) тарафыннан гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук әлеге Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

-автокую территориясенең бөтен периметрын механик һәм тышкы мохит тәэсир итүләренә чыдамлы койма белән әйләндереп алырга;

-автокую коймаларының тиешле техник хәлдә тотылуын, аларның чисталыгын күзәтеп торырга, пычрактан, кардан, боздан, мәгълүмати-басма продукциядән вакытында чистартып торырга;

-автокую территорияләрендә, автокую белән янәшә территорияләрдә материаллар туплауны, сүтелгән транспорт, төрле конструкцияләрне саклауны булдырмаска;

-автокую территорияләрен гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр таләпләренә җавап бирә торган, яктылыкның тигез таралуын тәэмин итүче тышкы яктырту белән җиһазларга;

-автокую территорияләрендә машина юуны, яну-майлау материаллары аккан автомобильләрне саклауны булдырмаска;

-автокую территорияләрен санитар һәм янгынга каршы кагыйдәләрне үтәп карап тотарга;

-даими рәвештә санитар эшкәртү һәм чистарту үткәрергә, калдыкларны җыю өчен контейнерлар (чүп савытлары) урнаштырырга, көнкүреш каты калдыкларын, карны даими чыгарып торуны тәэмин итәргә;

- инвалидларга автокую территорияләренә каршылыксыз үтү мөмкинлеген тәэмин итәргә. Инвалидлар махсус автотранспорт чараларын кую урыннарыннан 1995 нче елның 24 ноябреннән 181-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” Федераль законының 15 нче маддәсе нигезендә түләүсез файдаланалар.

**Авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү**

92. Авыл җирлеген бәйрәмчә бизәү истәлекле вакыйгалар белән бәйле дәүләт бәйрәмнәре һәм башка бәйрәмнәр, чаралар үткәрү вакытында башкарыла.

Бәйрәмчә бизәлеш дәүләт һәм муниципаль флагларын, лозунглар, гирляндалар, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар, трибуна, эстрадалар, шулай ук бәйрәм иллюминацияләре урнаштыруны үз эченә ала.

Бәйрәмчә бизәлеш элементларын ясау һәм урнаштыру вакытында юл хәрәкәтен көйләүнең техник чараларын алып кую, аларны зарарлау һәм аларның күренеп торуын начарайту рөхсәт ителми.

**IV. Җирлек территорияләрен, төзекләндерү эшләренең исемлеген һәм аларны башкаруның вакытын да кертеп, җыештыруның тәртибе. Җирлек территориясен җыештыру һәм карап тотуга гомуми таләпләр**

93. Авыл җирлеге территориясен җыештыру һәм карап тоту түбәндәгечә башкарыла:
1) җәйге чорда - 15 апрельдән 14 октябрьгә кадәр;
2) кышкы чорда-15 октябрьдән 14 апрельгә кадәр.

Әлеге срокларга, һава шартларына бәйле рәвештә, җирлек башкарма комитеты тарафыннан төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

94. Җирлек территориясен җыештыру түбәндәгеләрне юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) җирлек территориясен җыештыру, карап тоту буенча системалы эшләр башкару;

2) Башкарма комитетның хокукый актлары нигезендә каралган массакүләм чаралар (өмәләр) үткәрү.

95. Җирлек территориясен җәйге чорда җыештыру җирлек территориясенең пычрануын һәм тузанлануын киметү максатыннан юу, су сибү, себерү һәм җирлек территориясен карап тору буенча башка эшләр үткәрү юлы белән башкарыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-ясалма өслекле территорияләрне себерү (коры һава шартларында су сибү), яңгыр канализациясе белән җиһазландырылган урам-юл челтәре объектларының һәм ясалма өслекле башка территорияләрнең юл өслегеннән тузан һәм пычракны юу. Юл өслекләрен

, мәйданнарны, тротуарларны һәм башка ясалма өслекле территорияләрне юу өслекнең бөтен киңлеген алып башкару;

-яңгыр канализациясенең рәшәткәләрен чистарту;

-бөтен территориядән чүпләрне җыю;

-ел саен, 1 нче июньгә, кадәр кече архитектура формаларын, бакча һәм урам җиһазларын, чүп савытларын, спорт һәм балалар мәйданчыкларын, коймаларны, бордюрларны буяу;

-чикләнгән файдаланудагы һәм махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләрне исәпләмичә, гомуми файдаланудагы территорияләрдә үләнне даими рәвештә чабу (үлән биеклеге 15 см.дан артса), һәм чабылган үләнне тәүлек эчендә җыештыру;

-яфрак коелу чорында – тәүлеккә бер мәртәбә коелган яфракларны җыю һәм чыгару;

-юуны үткәргәннән соң, бордюр янындагы улакларны чүптән чистарту.

96. Гомуми кулланылыштагы территорияләрне кышкы чорда җыештыру үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-юл өсләрен һәм тротуарларны кардан, боздан һәм чүптән чистарту;

-бозлавык һәм тайгак барлыкка килгәндә – җәяүлеләр зоналарына, баскычларга ком сибү, юл өсләрен бозлавыкка каршы материал белән эшкәртү;

-язгы чорда – карны йомшарту һәм кар суларын агызу.

97. Җирлек территориясендә башкарыла торган җыештыру эшләренең технологиясе һәм режимнары, һава шартларына бәйсез рәвештә, транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итәргә тиеш.

98. Җәяүлеләр тротуарларын, тротуарларын, җир өсте кичүләрен , баскычларны кышкы вакытта җыештыру үзенчәлекләре:

-җәяүлеләр тротуарлары, баскычлар кар интенсив яуган вакытта бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә һәм чистартылырга тиеш;

-бозлавык барлыкка килгәндә бозлавыкка каршы материаллар белән беренче чиратта баскычлар, аннары тротуарлар эшкәртелә. Бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү вакыты тайгак билгеле булганнан соң дүрт сәгатьтән дә артмаска тиеш;

-калдыклар һәм химик реагентлар белән пычранмаган йомшак карны, яшел үсентеләрне зарарламау һәм кар сулары агып китүне тәэмин итү шарты белән, газоннарга яки башка бу максатлар өчен билгеләнгән урыннарга урнаштырырга рөхсәт ителә.

99. Җирлек территориясендә рөхсәт ителми:

-урамнарны, мәйданнарны, яшел үсентеләр булган участокларны, газоннарны, пляжларны һәм гомуми файдалануда булган башка территорияләрне чүпләргә;

- гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән җирләү урыннарыннан читтә булган гомуми файдалану территорияләрендә мемориаль кабер өсте корылмалары (истәлек корылмалары, чардуганнар) урнаштыру;

- бу максатлар өчен каралмаган урыннарда, шул исәптән җәмәгать транспорты муниципаль маршрутының соңгы тукталышларында транспорт чараларын юу, салоннарны чистарту һәм техник хезмәт күрсәтү;

-биналарны һәм корылмаларның төзекләндерү элементларын, һәйкәлләрне, мемориаль такталарны, агачларны, куакларны, кече архитектура формаларын һәм гомуми кулланылыштагы башка төзекләндерү элементларын җимерергә, аларга зыян китерергә, шулай ук аларны үз белдегең белән үзгәртеп ясау, үзгәртеп кору һәм башка урынга күчерү;

- җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, йорт диварларында, баганаларда, рәшәткәләрдә (койма) һәм башка бу максатлар өчен каралмаган объектларда граффити язу, ясау, мәгълүмати-басма продукцияне ябыштыру һәм элү;

-күчемле мөлкәтне тапшырылган җир кишәрлекләре чикләреннән һәм (яки) коймаларыннан читтә урнаштыру һәм саклау;

-тартмаларны, сәнәгать товарларын һәм башка сәүдә предметларын тротуарларда, газоннарда, юлларда тезү һәм урнаштыру;

-күрсәтелмәгән урыннарда кар өю;

- тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар , шлагбаумнар, корылмалар һәм башка җайланмалар куеп, үз белдегең белән юлларны һәм тротуарларны каплау.

100. Рөхсәтсез урыннарда калдыклар ташлаган затлар үз акчалары хисабына әлеге территорияне чистартартырга һәм җыештырырга, ә кирәк булганда - җир кишәрлегенә рекультивация үткәрергә тиеш.

20 тәүлек эчендә рөхсәтсез урында калдыклар ташлаган зат табылмаса, калдыкларны җыю һәм рөхсәтсез чүплекләр территорияләрен рекультивацияләү әлеге территорияне җыештыру өчен җаваплы оешмалар (яки калдыкларны чыгаруны, әгәр модый төр хезмәт килешү белән каралган булса, гамәлгә ашыручы специальләшкән оешма) тарафыннан башкарыла.

101. Билгеләнгән тәртиптә тапшырылмаган һәм муниципаль милектә булган җир участокларында (территорияләрдә) стихияле рәвештә барлыкка килгән чүплекләрне бетерү вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин ителә.

## Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын җыештыру

102. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (ары – юллар) җыештыру автомобильләр йөри торган өлешне, тротуарларны, парковкаларны (парковка кесәләрен), җәмәгать транспортын көтү тукталышларын, ясалма юл корылмаларын пычрактан, чүптән, кардан һәм боздан чистартуны үз эченә ала.

103. Язгы-җәйге чорда юлларны җыештыру юуны, су сибүне, тузаннарны бетерүне, себерүне үз эченә ала.

Көзге-кышкы чорда юлларны җыештыру чүпне, кар һәм бозны, пычракны җыештыру һәм чыгару, юлларга комлы-тозлы катнашма сибү, тротуарларга коры ком сибүне күз алдында тота.

104. Юл буенда урнашкан чүп савытларын көнгә бер мәртәбә, тукталыш мәйданчыкларында – көнгә ике мәртәбә чистарту.

105. Җәмәгать транспортын көтү павильоннары тузанланмаска, юылган һәм буялган булырга, рөхсәт ителмәгән мәгълүмати-басма продукциядән, граффитидан чистартылырга тиеш.

106. Юлларны җәйге җыештыруга аерым элементлар буенча таләпләр:

-автомобиль йөри торган өлеш төрле пычранулардан бөтен киңлегенә тулысынча чистартылырга һәм юылырга тиеш;

-ике метрлы улак зоналарында грунтлы-комлы утырымнар һәм пычранулар булмаска тиеш. Специальләшкән машиналар эшләгән аралыкта барлыкка килергә мөмкин булган ком кисәкчекләре һәм төрле вак чүпләр белән аз гына пычранулар рөхсәт ителә.

-юл кырыйлары эре габаритлы калдыклардан һәм башка чүпләрдән чистартылырга тиеш;

107. Юлларны кышкы чистартуга таләпләр:

-юлларны кышкы чистарту үз эченә түбәдәгеләрне ала:

автомобильләр йөри торган өлешне, җәмәгать транспортын көтү тукталышларын кардан һәм боздан чистарту, себерү, карларны эттерү һәм карларны чыгару.

108. Рөхсәт ителми:

- тротуарларга, автомобильләр йөри торган өлешкә һәм үтү юлларына квартал эчендәге юллардан, ишегалды территорияләреннән, предприятие, оешмалардан, төзелеш мәйданчыкларыннан, сәүдә объектларыннан 8.00 дән соң, шулай ук автомобильләр йөри торган өлешне чистартучы зат белән килешү булмаганда, кар, боз этеп чыгарырга һәм күчерергә;

-тротуарларда, җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, паркларда, скверларда, ишегалларында һәм яшел үсентеле территорияләрдә бозлавыкка каршы реагент сыйфатында техник тоз һәм сыек хлорлы кальций кулланырга;

-билгеләнгән тәртиптә килешенмәгән урыннарга кар чыгару һәм туплау;

-кар өемнәрен урнаштырырга:

-юл һәм урамнарның бер тигезлектә кисешкән урынында һәм тимер юлны кичүләр янәшәсендә күз күреме өчпочмагы зонасында;

-җәмәгать транспортын көтү тукталышларына 20 м дан якынрак;

-транспорт коймалары яки күтәренке бордюрлар белән җиһазландырылган юл участокларында;

-тротуарларда;

-янәшә территорияләргә керү юлларында;

-автотранспорт көпчәкләрендә юлларга пычрак һәм грунт алып чыгу;

- грунт, чүп-чарны, коела торган төзелеш материалларын, җиңел тартмаларны, киселгән агачларны брезент яки юлларны пычратуга юл куймаслык итеп башка материал белән капламыйча бер урыннан икенче урынга күчерү, шулай ук юлга, тротуарларга, юл кырыйларына яки юл янындагы газон полосасына түгелү мөмкинлеген булдырмаучы чаралар күрмичә төзелеш катнашмаларын һәм эретмәләрне (шул исәптән цемент-ком эремәсен, известь, бетон катнашмаларын) транспортларга.

**Кешеләрнең ял итү һәм халык күп була торган урыннарны җыештыру һәм санитар карап тору**

109. Кешеләрнең ял итү һәм халык күп була торган урыннарга түбәндәгеләр керә:

-мәйданнар, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары, җирлек урманнарында оештырылган ял итү урыннары, пляжлар;

-актив ял итү һәм тамаша чаралары урыннары – стадионнар, уен комплекслары, ачык сәхнә мәйданчыклары һәм б.ш.;

-сәүдә итү (ваклап сату базарлары, сәүдә комплекслары, стационар булмаган ваклап сату челтәре объектларының комплексы), җәмәгать туклануы, социаль-мәдәни билгеләнешле, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары территорияләре;

-административ һәм җәмәгать биналарына, учреждениеләргә килеп тоташа торган территорияләр

110. Мәйданнарны, паркларны, скверларны, бульварларны, яр буйларын һәм гомуми кулланыштагы башка территорияләрне җыештыру:

-кышкы вакытта парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, яр буйлары һәм башка ял итү урыннарында юлларны чистартканда, химик реагентлар белән пычранмаган йомшак карны, яшел үсентеләрне зарарламау һәм кар сулары агып китүне тәэмин итү шарты белән бу максатлар өчен алдан билгеләнгән урыннарга урнаштырырга рөхсәт ителә.

111. Ваклап сату базарларын җыештыру һәм санитар торышын карап тоту:

-ваклап сату базарлары территорияләре (ары – базар) төзекләндерелгән, бәдрәфләр, хуҗалык һәм контейнер мәйданчыклары, контейнерлар һәм чүп савытлары белән җиһазландырылган булырга тиеш, каты каплаулары һәм яңгыр һәм кар суларын агызу өчен авышлыклары, шулай ук сууткәргече һәм канализациясе булырга тиеш;

-базар территориясен төп җыештыру эшләре базар ябылганнан соң башкарыла. Көндез патрульле җыештыру һәм көнкүреш каты калдыклары белән тулган чүп савытларын чистарту эшләре башкарыла;

-елның җәйге чорында базар территориясендә мәҗбүри рәвештә атнага бер тапкыр юеш җыештыру башкарыла;

-базар территориясе 40 кв.м мәйданга 1 чүп савыты исәбеннән, чүп савытлары белән җиһазландырыла, алар арасындагы ераклык киштәләр линиясе буйлап 10 м дан артмаска тиеш.

112. Базар территориясендә һәм аның янында урнашкан оешмаларга, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләренә, киоскларга, сәүдә палаткаларына һәм

павильоннарга көнкүреш каты калдыкларын чыгару һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төземичә эшчәнлек алып барырга рөхсәт ителми.

113. Сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектларын җыештыру һәм санитар хәлен карап тору:

-сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектларын тулысынча җыештыру тәүлеккә кимендә ике тапкыр (иртән һәм кичен) башкарыла. Көндез патрульле җыештыру һәм көнкүреш каты калдыклары белән тулган чүп савытларын чистарту эшләре башкарыла;

-сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектларына керү урыннарына кимендә ике чүп савыты куела;

-калдыкларны чыгару тәэмин ителә.

114. Башка сәүдә мәйданчыкларын, стационар булмаган ваклап сату челтәре, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар территорияләрен җыештыру, елның җылы вакытында, алар ябылганнан соң, мәҗбүри алдан су сибеп башкарыла. Агымдагы җыештыру эшләре көн дәвамында башкарыла. Көнкүреш калдыкларын көндәлек чыгару тәэмин ителә.

115. Ял итү һәм кешеләрнең күп була торган урыннарын төзекләндерү:

-ял итү һәм кешеләрнең күп була торган урыннары территорияләрендә төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге каты өслек төрләрен (плитка яки асфальт), өслекләр бәйләнеше элементлары, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп савытлары һәм чүп-чар өчен кече контейнерлар, урам техник җиһазлары, яктырту җиһазларын, архитектур-декоратив яктырту җиһазларын, җирлекнең мәгълүмати күрсәткечләрен, яшелләндерү участокларын саклау элементларын (металл киртәләр, капламнарның махсус төрләре һәм б.ш.) үз эченә ала;

-ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган барлык территорияләрнең дә, пляжлардан тыш, каты катламлы өслегә яки үлән һәм яшел үсентеләр үскән өслекле җире булырга тиеш;

- ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарның территорияләрендә яшелләндерү участокларын чәчәк түтәлләре, газоннар, аерым, төркемләп, рәтләп утыртылган үсентеләр һәм яшелләндерүнең башка мобиль формалары рәвешендә проектларга кирәк;

- кешеләр күпләп йөри һәм ял итә торган урыннарда җиһазландырылган һәм эшли торган бәдрәф кабиналары урнаштырылырга һәм алар бәдрәфләрне урнаштыру һәм карап тоту таләпләрнә җавап бирергә тиеш.

- ял итү урыннары территорияләрендә яки кешеләр күпләп җыела торган урыннарда урнашкан фонтаннар, буалар, елга ярлары, пычранган саен, чистартылырга тиеш.

-массакүләм чаралар үткәргәндә, аларны оештыручылар чаралар үткәрелгән урыннарны җыештыруны һәм бозылган төзекләндерүне кабат торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Чаралар үткәрү урынын җыештыру һәм бозылган төзекләндерүне кабат торгызу тәртибе чараларны үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә тиешле рөхсәт итүне алган вакытта билгеләнә.

116. Ял итү һәм кешеләрнең күп була торган урыннарында рөхсәт ителми:

-әрҗәләр һәм сәүдә җиһазларын моның өчен каралмаган урыннарда саклау һәм урнаштыру;

-территорияне җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату;

-автотранспорт чараларын юу һәм ремонтлау, файдаланылган ягулык-майлау сыеклыкларын түгү;

-билгеләнгән тәртипне бозып, автокуюлар, гаражлар, аттракционнар төзү, реклама конструкцияләрен урнаштыру;

-газоннарны, табигый һәм ясалма яшелләндерү объектларын зарарларга;

-кече архитектура формаларын зарарларга һәм аларны урнаштырылган урыннарыннан күчерергә;

-сыек продукт калдыкларын, сатуратор җайланмаларындагы суларны, квас, пиво цистерналарын тротуарларга, газоннарга, җирлек юлларына түгәргә;

-законсыз рәвештә автотранспорт чараларын түләүле куюны оештыру;
-үз белдегең белән стационар булмаган объектларны урнаштыру;
-тротуарларның асфальт-бетон капламын, янәшәдәге яшел зоналарның һәм төзекләндерүнең башка элементларының бөтенлеген бозу;
-территориягә сәүдә-суыту җиһазлары чыгарып урнаштыру;
-көнкүреш каты калдыкларын, идарәче оешмалар белән калдыкларны контейнерларга (бункерларга) урнаштыру турында килешү төземичә, халыктан каты көнкүреш калдыклары җыю өчен билгеләнгән контейнерларга (бункерларга) салырга;
-тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар һәм башка җайланмалар урнаштырып, үз белдегең белән тротуарларны рөхсәтсез капларга;
-товарларны сәүдә объектларыннан читтә урнаштырырга;
- учак кабызырга, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрергә, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерләү өчен башка җайланмалар кулланырга.

**Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен җыештыру, карап тоту һәм төзекләндерү**

117. Йорт яны территориясен җыештыру:
- җыештыру алдагы тәртип буенча үткәрелергә тиеш: тротуарларны, җәяүлеләр юлларын (бозлавык һәм тайгак очрагында – ком сибү), ә аннары – ишегалды территорияләрен;
-җыештыру, кар яуганда башкарыла торган кар чистартудан башка, 8.00 гә кадәр үткәрелә.
Механикалаштырылган җыештыруны үткәрү көндезге вакытта машиналарның 4км/сәг. кадәр тизлегендә үткәрелә.
118. Җәйге җыештыру:
-йорт яны территорияләрен җәйге җыештыру: себерү, кулдан яки махсус машиналар ярдәмендә су сибү, юу – иртән, иртәнге, һәм соңгы, кичке, сәгатьләрдә үткәрелергә тиеш;
-тротуарлар юуны бары улак яны полосасы белән турыдан-туры чикләнүче ачык тротуарларда һәм биналардан юлларга таба юнәлештә башкарырга кирәк;
- эссе көннәрдә тротуарларга, зарурлыгына карап, ләкин көнгә ике тапкырдан да ким түгел су сиптерелә.
119. Кышкы җыештыру:
-түбәләрдә җыелган кар җиргә вакытында төшерелергә һәм улак яны полосасына эттерелергә, ә киң тротуарларда – өемнәргә тупланырга тиеш;
-җыештырыла торган кар тротуарлардан автомобиль йөрү юлларына таба улак яны полосасына, ә ишегалларында – кар туплау урыннарына эттерелергә тиеш;
-квартал эчләрендәге юллардан эттерелгән карны күчләргә һәм өемнәргә борт ташларына параллель рәвештә тупларга, яки автомобиль юллары кырыена, кагыйдә буларак, роторлы карчистарткычлар ярдәмендә урнаштырыла;
-автомобиль юлларыннан газон белән аерылган, киңлеге 6 м дан арткан тротуарларда карны соңыннан җыештыру өчен тротуар уртасына эттерергә мөмкин;
-карны өемнәргә һәм күчләргә туплау эше кар явып туктаганнан соң тротуарларда алты сәгатьтән соңрак булмаган, башка территорияләрдә 12 сәгатьтән соңрак булмаган вакыт эчендә тәмамланырга тиеш;
- ишегалларында, квартал эчендәге юлларда җыела торган ком-тоз катнашмалары белән пычранмаган карны, яшел үсентеләрнең сакланышын һәм эрегән кар сулары агып китүен тәэмин итү шарты белән, җәяүлеләрнең һәм автотранспортның тоткарлыксыз йөрүенә комачауламый торган газоннарда һәм буш территорияләрдә тупларга рөхсәт ителә;

-тротуарлардан һәм квартал эчендәге юлларны кулдан җыештырганда, кар тулысынча кыргыч белән чистартылырга тиеш. Камилләштерелгән юл өслеге булмаганда, карны движоккача, кар катламын соңыннан тыгызлау өчен калдырып, җыештырырга кирәк;

-тайгак барлыкка килгәндә юл өслекләре 0,2-0,3 кг/м нормасында ком-тоз катнашмасы белән тараткычлар ярдәмендә эшкәртелергә тиеш;

-эшкәртүдән соң йомшарган бозлар, ачык грунтка, агач төпләренә һәм газоннарга эләкмәслек итеп, эттерелергә яки себерелергә тиеш.

120. Яз җиткәч түбәндәгеләр башкарыла:

-кар суларының нормаль агуын булдырырга кирәк җирләрдә канауларны чистарту һәм юдыру;

-кар суларын системалы рәвештә яңгыр канализациясе люкларына һәм кабул итү коеларына кудыру;

-кар эрегәннән соң ишегалды территорияләрен чүптән, калган кар һәм боздан чистарту.

121. Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен карап тоту:

-күпфатирлы йортның йорт яны территориясен (ары – йорт яны территориясе) карап тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала:

-даими җыештыру;

-күзәтү һәм яңгыр коеларының люкларын һәм рәшәткәләрен, дренажлар, улаклар, һәм су агызучы торбаларны ремонтлау һәм чистарту;

-инженерлык челтәрләренең күзәтү коеларына, янгын вакытында су белән тәэмин итү чыганакларына (гидрантларга, сулыкларга һәм башкаларга) тоткарлыксыз якын килү мөмкинлеген тәэмин итү;

-көнкүреш каты һәм эре габаритлы калдыкларны җыю һәм чыгару;

-яшелләндерү һәм утыртылган яшел үсентеләрне карап тору;

-кече архитектура формаларын карап тору, чираттагы һәм капиталь ремонт ясау.

122. Бөтен төр калдыклар сууткәрмәүче өслекле контейнер мәйданчыкларына, көнкүреш каты калдыкларын туплау нормаларына туры китереп, тиешле санда куелган контейнерларга һәм бункерларга җыелырга тиеш.

123. Күпфатирлы йортларда яшәүче гражданнар түбәндәгеләргә бурычлы:

-йорт яны территорияләрендә чисталык һәм тәртип сакларга;

-көнкүреш каты һәм эре габаритлы калдыкларны бары йорт яны территорияләрендә урнашкан махсус контейнерларга һәм махсус мәйданнарга куярга.

124. Идарә итүче оешмалар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

-көнкүреш каты калдыклары өчен контейнерлар, ә канализация үткәрелмәгән йортларга моннан тыш көнкүреш сыек калдыклары өчен җыйгычлар да куюны;

-расланган график нигезендә каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны чыгару;

-контейнерларны (бункерларны) һәм контейнер мәйданчыкларын, аларга керү урыннарын чисталыкта һәм төзек хәлдә тоту;

-подъездларга керү юлларында эскәмияләр, чүп савытлары кую һәм аларны вакытында чистартып тору;

-тайгак урыннарны комлы-тозлы катнашмалар һәм (яки) махсус бозлавыкка каршы белән эшкәртү;

- яшел үсентеләрне һәм газоннарны саклау, квалификацияле карау;

-тышкы яктырту чараларының төзеклеген һәм караңгы төшү белән аларның кабызылуын тәэмин итү.

125. Йорт яны территориясендә рөхсәт ителми:

-яфракларны, калдыкларның теләсә нинди төрләрен һәм чүп-чарны яндыру;

-хуҗалык мәйданыннан читтә керләр, кием-салым, келәмнәр һәм башка предметларны элү;

- контейнер мәйданчыкларына керү юлларын каплау;

-урам һәм юлларның машиналар йөри торган өлешенә, тротуарларга, газоннарга һәм яшел зоналарга контейнерлар (бункерлар) кую;

-билгеләнгән тәртипне бозып, йорт яны территорияләренең коймаларын үз белдеге белән урнаштыру;

-үз белдеге белән ишегалды корылмалары төзү;

-йорт яны территориясен металлолом, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары, төзелеш материаллары, шлак, көл башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән тутыру, әрҗәләр урнаштыру һәм саклау;

-юынтык сулар түгү, калдыклар һәм чүп ташлау;

-транспорт чаралары өчен түләүле автокуюлар оештыру;

-үз белдеге белән квартал эчендәге юлларны тимербетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар объектлар, корылмалар һәм башка җайланмалар белән каплау;

-автомашиналарны юу, ягулык һәм май түгү, тавыш сигналларын, тормозлар һәм двигательләрне көйләү;

-кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган эшләр башкару;

-теләсә нинди сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре: палаткалар, киосклар, ларёклар, кече базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектлары, автомобильләргә, көнкүреш техникасына, аяк киеменә вак ремонт ясау предприятиеләрен дә кертеп, шулай ук автокуюлар (кунакларныкыннан башка) урнаштыру;

-йорт яны территориясенең ишегалды эчендәге юлларыннан транспортның транзит хәрәкәтен булдыру;

-учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерләү өчен башка җайланмалар куллану.

126. Идарә итүче оешмалар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

-яшел үсентеләрне саклауны;

-җәен коры һава шартларында газоннарга, чәчәклекләргә, агач һәм куаклыкларга су сиптерүне;

-төзелеш материаллары, ком, чүп, кар, боз кителкләре урнаштырмыйча газоннарның саклануын һәм бөтенлеген;

- бары билгеләнгән тәртиптә килешенгән проектлар буенча агротехник шартларны саклап агач һәм куакларны яңадан утыртуны, юл челтәрен үзгәртү һәм җиһазлар урнаштыруны кертеп яңадан планлаштыруны .

127. Йорт яны территориясен төзекләндерү:

-һәр йорт хуҗалыгында , кагыйдә буларак, булырга тиеш:

-кер киптерү, кием, келәм, һәм көнкүреш предметларын чистарту өчен хуҗалык мәйданчыгы;

-олылар ял итә торган мәйданчык;

-балаларның җәйге һәм кышкы ялы өчен яшелләндерелгән һәм кирәкле кече архитектур формалар белән җиһазландырылган балалар уен һәм спорт мәйданчыклары.

128. Әгәр участок территориясенең үлчәме мөмкинлек бирсә, участок чикләрендә этләрне йөртү өчен мәйданчык урнаштырырга мөмкин.

129. Йорт подъездлары каршындагы мәйданчыклар, машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган юллар каты өслекле булырга тиеш. Каты өслек урнаштырылганда кар һәм яңгыр сулары агу мөмкинлеге каралырга тиеш.

130. Торак йортларда урнаштырылган җәмәгать билгеләнешендәге биналарга йортның торак өлешеннән изоляцияләнгән керү юллары булырга тиеш, шул ук вакытта персонал транспортын калдыру урыны ишегалды территориясеннән читтә урнашырга тиеш.

131. Торак йорт тәрәзәләре һәм фатирларга керү ишекләре урнашкан ишегалды ягыннан җәмәгать билгеләнешендәге биналар өчен материаллар, продукция төяү рөхсәт

ителми. Төяүне торак йортларның тәрәзәсез арткы ягыннан, җир асты тоннельләреннән яки юл ягындагы ябык дебаркадерлардан башкарырга кирәк.

132. Эчке квартал территориясенә автотранспорт чараларын кую кешеләрнең, шулай ук чистарту һәм махсус техниканың каршылыксыз хәрәкәтен тәэмин итәргә тиеш.

**Шәхси торак төзелеше территорияләрен җыештыру**

133. Торак йорт хуҗалары җир участогында көндәлек җыештыру (шул исәптән кардан) үткәрәләр.

134.Рөхсәт ителми:

-йорт хуҗалыгы территориясеннән кар эттереп чыгарырга, чүп ташларга, шлак чыгарырга, сыек көнкүреш калдыкларын түгәргә;

-автомобиль йөрү юлларына ишегалды территориясеннән чистартылган кар һәм бозны этеп чыгарырга яки күчерергә;

-йорт хуҗалыгы территориясеннән читтә яфрак һәм теләсә нинди калдык һәм чүпне яндырырга;

-йорт хуҗалыгына тоташа торган территориягә үз белдеге белән коймалар урнаштыру;

-янәшәдәге территорияне металлолом, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары, төзелеш материаллары, шлак, көл башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән тутыру;

-үз белдеге белән юлларны тимербетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар объектлар, корылмалар һәм башка җайланмалар белән каплау;

-кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган эшләр башкару;

## V. Территорияне төзекләндерү элементларына таләпләр

135. Территорияне төзекләндерүнең аерылгысыз компонентлары булып торган территория төзекләндерү элементлары гамәлдәге законнар таләпләренә туры китереп проект документациясендә эшләнергә һәм каралырга тиеш.

Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында урнашкан территорияләрнең төзекләндерү элементларына проект документациясе мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтле органнар белән килештерелә.

Территорияне төзекләндерүнең озак һәм даими кулланылыштагы стационар элементлары, аларны кулдан күчерергә мөмкинлек бирми торган итеп беркетелергә тиеш.

136. Төзекләндерү элементларын карап тотуны, аларны торгызу һәм ремонтлау эшләрен дә кертеп, төзекләндерү элементларының хуҗалары гамәлгә ашыра.

**Яшелләндерү**

137. Яшел үсентеләр территорияне төзекләндерүнең мәҗбүри элементы булып тора.

Төзекләндерү буенча эшләр үткәргәндә булган яшел үсентеләрне максималь саклау мөһим.

138. Җирлек территориясендә яшелләндерүнең ике төре кулланылырга мөмкин: стационар - үсемлекләрне грунтка утырту һәм мобиль - үсемлекләрне махсус күчмә савытларга (контейнерлар, вазоннар һәм башкаларга) утырту.

Стационар һәм мобиль яшелләндерүне архитектур-ландшафт объектларын (газоннар, бакчалар, чәчәклекләр, куаклар һәм агачлар утыртылган мәйданчыклар һәм б.ш.)

рельефның табигый һәм ясалма элементларында, биналарның һәм корылмаларның түбәләрендә (түбә яшелләндерүе), фасадларында (вертикаль яшелләндерү) ясау өчен кулланалар.

139. Яшелләндерү объектларын карап тоту – яшел үсентеләрне һәм яшелләндерелгән территорияләрнең төзекләндерү элементларын карап тоту, күләмле корылмаларның конструктив элементларының зур булмаган деформацияләрен һәм ватылуларын төзәтү, шулай ук җәйге һәм кышкы вакытта күчмә кече формаларны җыештыру буенча эшләр комплексы.

140. Яшел үсентеләрнең хуҗалары түбәндәгеләргә бурычлы :

-яшел үсентеләрне саклауны һәм квалификацияле карауны тәэмин итәргә;

- җәй көне һәм коры һава шартларында газоннарга, чәчәк түтәлләренә, агачларга һәм куакларга су сибәргә;

-газоннарның бөтенлеген һәм саклауны тәэмин итәргә;

-яшелләндерү объектларында сулыклар булган очракта аларны чисталыкта тотарга һәм 10 елга бер тапкырдан да ким булмаган капиталь чистарту эшләре үткәрергә;

141. Яшелләндерелгән территорияләрдә рөхсәт ителми:

-яшелләндерү эшчәнлеген тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән төзелешләрдән тыш башка төзелешләр алып бару;

-үз белдегең белән агач һәм куак утырту яки кисү, газоннарны һәм чәчәк түтәлләрен юк итү;

-агачларга һәм башка яшел үсентеләргә гамаклар, атынгычлар, турниклар, кер киптерү өчен баулар эләргә, агачларга реклама һәм башка мәгълүмат урнаштыруга каралган реклама һәм мәгълүмат такталары һәм табличкалар, чыгарылма конструкцияләр, объектларга хәрәкәт юнәлеше күрсәткечләре, афишалар, белдерүләр, агитация материаллары, техник конструкцияләр, юл хәрәкәтендә катнашучыларны мәгълүмати тәэмин итү чаралары, баганалар тарттырмалары, коймалар, реклама такталары, электр чыбыклары, лампалар, чәнечкеле киртәләр беркетергә;

-елның кайсы вакытына карамастан стационар булмаган объектлар, шулай ук юл сервисы объектлары урнаштыру;

-төзелеш һәм башка материалларны, калдыкларны, чүпне, бозлавыкка каршы һәм башка агулы матдәләрне, шулай ук ком һәм бозлавыкка каршы реагентлар белән пычранган кар, боз кисәкләрен урнаштыру;

- яшелчә бакчасы итеп казу;

-газоннарда һәм чәчәк түтәлләрендә йорт хайваннарын йөртү;

-яфракларны, үләнне, ботакларны яндыру, шулай ук аларны су агу юлларына һәм башка сууткәргеч җайланмаларга салу;

-газоннарга себерелгән чүпне ташлау;

- учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерләү өчен башка җайланмалар куллану;

-агачларның кәүсәләрен сок, сумала алу өчен кисү, аларга механик җәрәхәтләр ясау;

-яшелләндерелгән территорияләрдә урнашкан скульптураларны, эскәмияләрне, коймаларны, чүп савытларын, балалар һәм спорт җиһазларына зарар китерергә;

- агачларның тамырларын кәүсәсеннән 1,5 метрдан якын ераклыкта ачу һәм агачларның тамыр муентыкларын җир яки төзелеш калдыклары белән күмү.

## Коймалар

142. Койма корылмалары төзекләндерүнең өстәмә элементы булып тора.

143. Коймалар түбәндәгеләр буенча аерылалар:

- билгеләнеше (декоратив, саклау, аларның кушылмасы);

- биеклеге (тәбәнәк – 1,0 м га кадәр, урта – 1,1-1,7 м, биек – 1,8 – 3,0 м);

- материалы төре (металл, тимер-бетон һәм б.);
- үтә күренмәлелек дәрәҗәсе (үтә күренмәле, аркылы күренми торган);
- стационарлык дәрәҗәсе (даими, вакытлы, күчмә);

Коймаларны проектлау аларның урыны, билгеләнешенә бәйле рәвештә гамәлдәге дәүләт стандартларына, сертификация үткән эшләнмәләр каталогына, индивидуаль проектлаштыру проектларына нигезләнеп башкарыла.

144. Мәдәни мирас объектлары территорияләрен коймалауны әлеге территорияләр өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә башкарырга кирәк.

**Өслекләрнең япмалары**

145. Өслекләрнең япмалары җирлек территориясендә куркынычсыз һәм уңайлы хәрәкәт итүне тәэмин итә, шулай ук барлыкка килгән җирлек төзелешенең архитектур күренешен билгели.

Төзекләндерү максатлары өчен түбәндәге төр япмалар билгеләнә:

-каты (капиталь) япмалар – шул исәптән асфальт-бетоннан, цемент-бетоннан, табигый таштан ясала торган монолит яки җыелма япмалар;

-йомшак (капиталь булмаган) япмалар – табигый яки ясалма коелучан материаллардан (шул исәптән ком, вак таш, гранит чәчмәләр, керамзит, резина валчыклары) ясала торган табигый халәттәге, коры катнашмаларда, бәйләүче материаллар белән тыгызланган яки ныгытылган япмалар;

-газон япмалары – үлән капламын әзерләү һәм утыртуның махсус технологияләре буенча ясала торган япмалар ;

-катнаш япмалар – төрле япмалар кушылмасы (газонга батырылган рәшәткәле плитка яки газон рәшәткәсе, яки йомшак япма)

146. Япмалар төрен сайлауны аларның максатчан билгеләнешенә туры китереп гамәлгә ашырырга кирәк:

-катыларны – проектлау моментына гамәлдәге мөмкин булган соң чик авырлыкны, хәрәкәтнең характерын һәм составын, янгынга каршы таләпләрне исәпкә алып;

- йомшакларны – аерым төр территорияләрне (шул исәптән балалар , спорт мәйданчыклары, этләрне йөртү мәйданчыклары, йөрү сукмаклары) төзекләндергәндә аларның үзенчәлекле сыйфатларын исәпкә алып;

- газон һәм катнаш япмаларны экологик яктан өстенрәк.

Каты төр япмалар ябыштыру коэффициенты коры халәттә 0,6 дан, юеш халәттә 0,4 тән ким булмаган кытыршы өслекле булырга тиеш.

**Өслекләрне тоташтыру**

147. Өслекләрне тоташтыру элементларына гадәттә төрле төр борт ташлары, пандуслар, басмаларны, баскычларны кертәләр.

**Борт ташлары**

148. Юл борт ташлары тротуар белән автомобиль юллары тоташкан урында юл өслегеннән кимендә 150 мм норматив биеклектә куела, юл япмалары өстенә ремонт ясау очрагында да сакланырга тиеш.

Автотранспортның газонга керүен булдырмас өчен, автомобиль юлы япмасының газон белән тоташкан урынында биегәйтелгән борт ташы кулланырга кирәк.

Җәяүлеләр коммуникацияләре япмасы газон белән тоташкан җирләрдә кимендә 0,5 м аралыгында, газон өслегеннән кимендә 50 мм биеклек бирә торган бакча борты урнаштырырга мөмкин, ул газонны саклый һәм япмага пычрак һәм үлән чүпләре эләгүне булдырмый, аның хезмәт итү срогын озынайта.

Җәяүлеләр зоналары территориясендә төрле типтагы япмалар тоташкан урыннарны ясау өчен табигый материаллар (кирпеч, агач, йомры ташлар, керамик борт һ.б.) файдаланырга мөмкин.

**Басмалар, баскычлар, пандуслар**

149.Җәяүле коммуникацияләренең авышлыгы 60 промилле дән артык булганда баскычлар урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм халык күп килә торган башка объектлар, инвалидлар һәм картлар йортлары урнашкан урыннарда төп җәяүле коммуникацияләрендә авышлыклар 50 промилле дән артса, мәҗбүри рәвештә пандуслар белән тәэмин итеп, басмалар һәм баскычлар күздә тотылырга тиеш.

Бордюр пандусының авышлыгы 1:12 исәбендә кабул ителә.

Төшкәндә һәм менгәндә баскычларның беренче басма кырыйларын ачык контраст төстәге полосалар белән аерып күрсәтергә кирәк.

Тышкы баскычларның бөтен басмалары бер марш чигендә киңлеге һәм биеклеге бер төсле басмалар белән урнаштырыла.

Пандусны чикләүче конструкцияләр булмаганда, биеклеге кимендә 75 мм һәм тоткычлары булган киртәләп торучы бортиклар урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Пандус башланган һәм беткән урыннардагы юлның горизонталь участоклары әйләнә-тирә өслекләрдән аерылып торган текстура һәм төс белән эшләнә.

Баскычның яки пандусның ике ягыннан да 800-920 мм биеклегендәге түгәрәк яки турыпочмаклы, кул белән тоту өчен уңайлы һәм стенадан 40 мм ераклыкта торучы тоткычлар куюны күз алдында тотарга кирәк.

**Мәйданчыклар**

150. Торак пункты территориясендә мәйданчыкларның түбәндәге төрләре урнаштырыла: балалар уйнау, өлкәннәр ял итү, спорт белән шөгыльләнү, чүп җыю савытлары урнаштыру, этләрне йөртеп керү һәм дрессировкалау, автомобильләр кую өчен.

Регистрация үткән мәдәни мирас һәйкәлләрен саклау зоналары һәм аеруча саклана торган табигый территорияләр зоналары чикләрендә мәйданчыклар урнаштыруны һәйкәлләрне саклау, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтле органнар белән килештереп урнаштырырга киңәш ителә.

Йорт яны территорияләре, кагыйдә буларак, балалар уен һәм спорт мәйданчыклары белән тәэмин ителергә тиеш.

**Балалар мәйданчыклары**

151. Балалар мәйданчыклар төрле яшь төркемнәре өчен аерым мәйданчыклар рәвешендә яки төрле яшьтәгеләрнең кызыксынулары буенча зоналарга аерылган комплекслы уен мәйданчыклары рәвешендә оештырылырга мөмкин.

Балалар мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек япмаларының йомшак төрләре, мәйданчык өслегенең газонга тоташу элементлары, яшеллек, уен җайланмалары, эскәмияләр һәм чүп савытлары, яктырту җиһазлары.

Торак йортларның һәм җәмәгать биналарының тәрәзәләреннән балалар мәйданчыклары чикләренә кадәр ара мәктәпкәчә яшьтәге балаларныкы 10 м дан ким, кече һәм урта яшьтәге балаларныкы – 20 м дан ким, комплекслы уен мәйданнарыныкы – 40 м дан, спорт-уен комплексының – 100 м дан ким булмаска тиеш.

Балалар уен мәйданчыклары контейнер мәйданчыкларыннан 20 м дан да кимрәк булмаган ераклыкта урнашкан булырга тиеш.

152. Балалар мәйданчыклары:
-җәйге вакытта тигезсезлекләргә ком сибүле планировкасы булырга тиеш;
-иртәнге вакытта себерелергә һәм юешләнлерелергә тиеш;
-буялган булырга тиеш, мәйданчыктагы коймалар һәм корылмалар елга бер тапкырдан ким булмаганча буялырга тиеш, ә ремонт - кирәк булганда;
-транзит җәяүлеләр хәрәкәтеннән, автомобиль юлларыннан, борылыш ясау мәйданчыкларыннан, кунак машиналар тору урыныннан, калдыклар өчен контейнерлар кую мәйданчыкларыннан, автотранспорт чараларын даими һәм вакытлы саклауга кую участокларыннан изоляцияләнгән булырга тиеш.

Травматизм очракларын булдырмау өчен балалар мәйданчыкларында җирдән чыгып торган тамырларның яки асылынып торган ботакларның, җир өстендә иске, киселгән җиһазларның (баганалар, фундаментлар) калдыклары, җиргә күмелмәгән металл җайланмаллар (кагыйдә буларак, турникларның, таганнарның) булмаска тиеш.

Янәшә торучы территорияләрне реконструкцияләгәндә балалар мәйданчыклары территорияләрендә эшләр алып бару һәм төзелеш материалларын урынлаштыру рөхсәт ителми.

Яктырту җиһазлары, кагыйдә буларак, мәйданчык урнашкан территорияне яктырту режимында эшләргә тиеш.

Яктырту җиһазларын 2,5 м дан да кимрәк биеклектә куярга рөхсәт ителми.

Уен җиһазларын урнаштыру куркынычсызлыкның норматив параметрларын исәпкә алып башкарылырга тиеш.

153. Балалар мәйданчыкларын карап тоту һәм аларда куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен җаваплылык аларны карап торуны гамәлгә ашыручы затларга йөкләнә.

### Спорт мәйданчыклары

154. Спорт мәйданчыклары халыкның яшь буенча барлык төркемнәре өчен физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән.

Спорт мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек япмасының йомшак яки газон төрләре (җәйге вакытта), спорт җиһазлары.

Спорт мәйданчыклары яшелләндереләләр һәм сеткалы киртәләр белән белән киртәләнәләр. Яшелләндерү мәйданчыкның периметры буенча урнаштырыла, вертикаль яшелләндерү кулланырга мөмкин. Киртәләрнең биеклеге 2,5-3 м, мәйданчыкларның бер-берсенә тоташкан урыннарында кимендә 1,2 м.

Спорт җиһазлары спорт һәм физкультура мәйданчыкларында яки махсус җиһазландырылган җәяүлеләр коммуникацияләрендә (сәламәтлек сукмакларында) рекреацияләр составында урнаштырыла. Спорт җиһазлары махсус физкультура снарядлары һәм тренажёрлары сыйфатында завод эшләнмәләре дә, шулай ук травма алуны булдырмый торган итеп (ярыклар, тишекләрнең булмавы һ.б.) өслеге махсус эшкәртелгән бүрәнәләрдән һәм бруслардан эшләнергә дә мөмкин.

Урнаштырганда сертификация алган җиһазлар каталогларына таянып эш итәргә кирәк.

### Ял итү мәйданчыклары

155. Торак төзелеше территориясендә өлкән буын кешеләренә тыныч ял итү һәм өстәл уеннары өчен билгеләнгән ял мәйданчыклары оештыру мөмкин.

Торак йортларның тәрәзәләреннән ял итү мәйданчыкларының чикләренә кадәр ара 10 м дан ким булмаска тиеш, шаулы өстәл уеннары мәйданчыкларына кадәр – 25 м дан ким булмаска тиеш.

Ял мәйданчыгында төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге: каты өслек төрләре, газонлы мәйданчык өслеген тоташтыру элементлары, яшелләндерү, ял итү өчен эскәмияләр һәм өстәлләр, чүп савытлары (һәр эскәмия янында кимендә берәр), яктырту җиһазлары.

Мәйданчык өслеген плитка түшәү рәвешендә проектларга тәкъдим ителә. Ял итү мәйданчыклары һәм балалар мәйданчыклары бергә булганда балалар уеннары зонасында каты өслек урнаштыруга юл куймаска киңәш ителә.

Парклар территорияләрендә үләндә ял итү өчен мәйданчыклар оештырылырга мөмкин.

**Этләр йөртү өчен мәйданчыклар**

156. Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар вәкаләтле органнар белән билгеләнгән тәртиптә килешенгән урыннарда урнаштырыла.

Этләрне урамда йөртү мәйданчыгы территориясендә төзекләндерү элементлары исемлеге: төрле өслек төрләре, коймалар, эскәмияләр, чүп савытлары, экскрементларны утилләштерү өчен контейнер, яктырту җайланмалары һәм мәгълүмати җиһазлар. Периметр буенча яшелләндерү тәкъдим ителә.

Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар микрорайонның һәм торак районның гомуми файдалану территорияләрендә яшел зоналардан читтәге буш урыннарда, метрополитен линияләренең техник зоналарында һәм гомумҗирлек магистральләрендә, 110 кВт көчәнештән артык булмаган электр тапшыру линияләре астында, беренче һәм икенче поясларны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар зонасыннан читтә урнаштырылырга тиеш.

Торак билгеләнешендәге территорияләрдә урнашкан мәйданчыклар зурлыгы 400-600 кв.м чикләрендә кабул ителә, башка территорияләрдә – 800 кв.м га кадәр, барлыкка килгән төзелеш шартларында булган территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, мәйданчыкларның зурлыгын киметергә мөмкин.

Мәйданчык чигеннән торак һәм җәмәгать биналары тәрәзәләренә кадәр ара 25 м дан ким булмаска тиеш, ә балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыкларына кадәр ара 40 м дан ким булмаска тиеш.

Мәйданчык коймасы, кагыйдә буларак, биеклеге 1,5 м дан ким булмаган җиңел металл челтәрдән эшләнә. Койманың элементлары һәм секцияләре , аның аскы кыры һәм җир арасындагы ераклык хайванга мәйданчыктан чыгу яки үзенә травма ясау мөмкинлеген бирмәскә тиеш.

Мәйданчык территориясендә мәйданчыктан файдалану кагыйдәләре язылган мәгълүмати стенд урнаштырылган булырга тиеш.

157. Йорт хайваннарының хужалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль җыештыру һәм утильләштерү эшен башкаралар.

Хайваннарның хуҗалары үзләренең хайваннарының башка хайваннарга һәм кешеләргә куркыныч йогынтысын булдырмый калырга, шулай ук тирә-юньдәгеләр өчен санитар нормалары нигезендә тынычлыкны тәэмин итәргә, гамәлдәге санитар-гигиена һәм ветеринария кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

**Автомобильләр кую мәйданчыклары**

158. Җирлек территориясендә түбәндәге төр мәйданчыклар урнаштырыла: автомобильләрне кыска вакытлы һәм озак саклау мәйданчыклары.

Автотранспорт чараларын кыска вакытлы һәм озак саклау участокларында төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге: өслекнең каты төрләре, , өслекләрнең тоташтыру элементлары, коймалар, чүп савытлары яки чүп өчен кече контейнерлар, яктырту җиһазлары, мәгълүмат җиһазлары (күрсәткечләр).

Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннарына керү юллары җәяүлеләр юлларының төп юнәлешләре белән кисешергә тиеш түгел.

Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыны аша җәяүлеләрнең транзит юлларын оештыру рөхсәт ителми.

Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыны калган территориядән киңлеге 3 м дан да ким булмаган яшел үсентеләр полосасы белән аерылырга тиеш.

**Кече архитектура формалары**

159. Кече архитектура формаларын урнаштыру төзелеш, биналарны һәм корылмаларны реконструкцияләү, һәм капиталь ремонтлау проект документларының “Төзекләндерү” бүлеге нигезендә, шулай ук төзекләндерү яки эскиз тәкъдимнәре проектлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кече архитектура формаларын проектлаганда һәм сайлаганда сертификацияләнгән эшләнмәләр каталогларыннан файдаланырга киңәш ителә. Тарихи төзелешләр, җирлекнең үзәге, торак пунктның күп функцияле үзәкләр һәм зоналар өчен кече архитектура формалары шәхси проект эшләнмәләре нигезендә башкарылырга тиеш.

160. Кече архитектура формаларына карата таләпләр:

-архитектура һәм ландшафт тирәлегенең характерына, территорияне төзекләндерү элементларына туры килү;

-материалларның югары декоратив һәм эксплуатацияләү сыйфатларына ия булуы, аларны тышкы мохит йогынтысын исәпкә алып озак вакыт дәвамынды саклануы;

-конструкцияләрнең, ышанычлылыгы, куркынычсызлыгы.

**Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары**

161. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан матур булырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары, оешма турында элмә такталардан һәм аның режимы турында табличкалардан тыш, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорт нигезендә һәм аңа тулысынча туры китерелеп урнаштырыла һәм эксплуатацияләнә.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чараларының хуҗалары аларның торышын күзәтеп торырга, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын вакытында ремонтларга һәм җыештырырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чараларын аларга реклама яки мәгълүмати хәбәр язмыйча урнаштыру һәм эксплуатацияләү, мәгълүмат кырына зыян китерү, шулай ук тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чараларын полиэтилен пленка һәм башка материаллар белән каплау рөхсәт ителми.

Реклама яки мәгълүмати конструкция хуҗасы территоря төзекләндерүне һәм (яки) фасадның тышкы күренешен монтаждан (сүтүдән) соң өч көн эчендә торгызырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары, аларның фундамент блогы булганда, фундамент блогы белән бергә сүтелергә тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштырганда корылмаларга һәм объектларның бизәлешенә зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын, һәм тотрыклылыгын киметү рөхсәт ителми.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

- дивар конструкциясе;
- декоратив панно;
- консоль конструкциясе;

- түбә конструкциясе;
- витрина конструкциясе;
- оешма элмә тактасы;
- режим турында табличка;
- модульле конструкция;
- стела;
- щит конструкциясе;
- флаглы композиция;
- махсус конструкция.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларына гомуми таләпләр:

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларын проектлау, әзерләү һәм урнаштыру Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Россия Федерациясе законнары таләпләренә, аларны саклау һәм куллану таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырылырга тиеш;

Тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт теле турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш;

Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл булырга, дөрес һәм аермачык башкарылырга тиеш тиеш.

**Гражданнарның белдерүләрен, мәдәни һәм спорт чаралары турында афишаларны урнаштыру**

162. Белдерүләрне, мәдәни һәм спорт чаралары турында афишаларны гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм җәяүлеләр күп йөри торган зоналарда бары тик махсус тумбаларда, щитларда һәм стендларда урнаштыру рөхсәт ителә.

Белдерүләр өчен стендлар аерым торучы объектлар рәвешендә яки биналарга яки корылмаларга беркетелә торган щитлар рәвешендә урнаштырылырга мөмкин.

**VI. Коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә җир эшләре башкаруга төп таләпләр**

163. Грунтны актару яки юл катламнарын ачу (җир асты коммуникацияләрен сузу, реконструкцияләү яки ремонтлау, свай һәм шпунтка кагу, электр тапшыру линияләре, элемтә баганаларын урнаштыру (алмаштыру), яктырту баганалары, грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында һәм башка эшләр) белән бәйле эшләр вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән язма рөхсәт (җир эшләрен башкаруга ордер) булганда гына башкарыла.

164. Җирлек территориясен төзекләндерү белән бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү тәртибе, җир эшләрен башкаруга ордер ясау һәм алу муниципаль хокукый актларның билгеләнгән таләпләре нигезендә башкарыла.

165. Яшел үсентеләрне бетерү яки күчереп утырту кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетның боерыгын алырга һәм яшел үсентеләрне алып ташлау яки күчереп утырту эшләрен башкарырга кирәк.

166. Җирлек юллары буенча хәрәкәтне вакытлыча чикләү яки туктату, мәҗбүри рәвештә юлның ике ягында заказчылар һәм эш башкаручылар, эшнең сроклары, әйләнеп үтү маршрутлары турында кирәкле барлык мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат щитын урнаштырып, вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән щитның формасы һәм эчтәлеге рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең тиешле административ регламенты белән билгеләнә.

167. Яраклылык вакыты чыккан ордерлар буенча башкарылса, коммуникацияләрне төзү, ремонтлау һәм реконструкция вакытында башкарылган җир эшләре үзбелдекле дип танылa.

## VII. Уңайлы мохиткә махсус таләпләр

168. Торак мохитен, урамнарны һәм юлларны, мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын төзекләндерүне проектлаганда өлкән яшьтәге кешеләр һәм инвалидлар өчен уңайлы мохиттән файдалану мөмкинлеген, әлеге объектларны картлар һәм инвалидлар хәрәкәтенә булыша торган элементлар һәм техник чаралар белән тәэмин итүне күздә тотарга тәкъдим ителә.

Өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар хәрәкәтенә ярдәм итә торган техник чараларны проектлау, төзү, урнаштыруны расланган проект нигезендә заказчы тарафыннан яңа төзелеш вакытында башкарырга тәкъдим ителә..

## VIII. Йорт хайваннары һәм кошларны карап тоту

169. Йорт хайваннарын һәм кош-кортларны карап тоту өченче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш. Йорт хайваннары һәм кошлар китергән зыян өчен гамәлдәге Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә аларның хуҗалары җаваплы.

170. Йорт хайваннары хуҗалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль рәвештә җыештыруны һәм утильләштерүне башкаралар.

171. Авыл хуҗалыгы терлекләрен (сыер, сарык, кәҗә, дуңгызлар һәм башкалар) һәм кошларны асрау авыл җирлегендә яшәүчеләргә йорт яны участоклары булган шәхси йорт территориясендә рөхсәт ителә.

172. Продукция бирүче хайваннар (мөгезле эре терлек, кәҗәләр, сарыклар, дуңгызлар, атлар) гражданнарның – хайваннарның хуҗаларының яшәү урыны буенча ветеринар оешмаларында биркалау юлы белән мәҗбүри теркәлергә һәм ел саен кабат теркәлү узарга тиеш.

173. Йорт хайваннарын көтү җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнгән көтү урыннарында хуҗасы күзәтүе астында яки аның кушуы буенча башка затның күзәтүе астында рөхсәт ителә.

174. Йорт хайваннарын 7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр урамда йөртү рөхсәт ителә. Башка вакытта урамда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү чаралары күрергә тиеш.

175. Өч айга кадәрге эт балаларын һәм кечкенә этләрне (әгәр алар махсус сумкада (контейнерда) яки аларны урамда йөртүче зат кулында булса) йөртү очракларыннан тыш, этләрне урамда йөртү, чылбыр (этне тотып торучы бүтән җайланма), муенчак һәм борынчак кулланып башкарылырга тиеш. 2014 нче елның 7 нче мартыннан16-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турындагы” Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә тиеш. Этләрне бәйдән ычкындырып йөртү торак пунктлардан читтә, шулай ук мондый йөртүне рөхсәт итүче билгеләр куелган урыннарда рөхсәт ителә.

176. Йорт хайваннары һәм кошлары тарафыннан тротуарларның, урамнарның, паркларның, газоннарның, балалар мәйданчыклары, скверларның, мәйданнарның, шулай ук торак йортларның подъездларын пычратуга хуҗалары юл куймаска тиеш. Эт, мәчеләр һәм башка вак хайваннарны урамда йөрткәндә, хуҗасы аларның мәйданчыклардагы чүп

контейнерларына ташланырга тиешле табигый яшәеш калдыкларын тулысынча җыюны тәэмин итә торган кирәк-яраклары булырга тиеш.

177. Этләрне бәйдән махсус йөртү урыннарында гына ычкындырырга ярый. Махсус билгеләнгән мәйданчыклар булмаганда, җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган бушлыкларда, сөзәклекләрдә йөртергә рөхсәт ителә.

178. Этләрне өйрәтү (дрессировка) бары тик яхшылап коймаланган мәйданнарда яки җирлек территориясеннән читтә башкарыла ала.

179. Йорт хайваннарын юл буйлап бары тик тәүлекнең якты вакытында һәм юлның уң ягына якынрак итеп куып алып барырга мөмкин. Йорт хайваннарын асфальт түшәлгән юл буенча грунт юллары һәм сукмаклар булмаганда гына йөртергә мөмкин.

180. Урамда йорт хайваннарын караучысыз калдырганда, хайваннарның хуҗалары яшел үсентеләргә килгән зыянны һәм загонда тоту чыгымнарын түлиләр.

181. Йорт кәҗәләре бары йорт яны территориясе эчендәге загоннарда яки хуҗалары күзәтүе астында көтүлекләрдә асралырга тиеш.

182. Рөхсәт ителми:

-малларны балалар һәм спорт мәйданчыкларында, пляжларда, мәгариф һәм медицина оешмалары территорияләрендә йөртү;

-йорт хайваннарын гражданнарның күпләп ял итү урыннарында урнашкан пляжларда йөртү һәм аларны сулыкларда коендыру;

-тыючы язулар булганда хайваннарны оешмаларга кертү;

-хайваннар һәм кошларны торак пункт территорияләренә караучысыз чыгарырга;

-алкоголь, наркотик һәм токсикологик исереклек хәлендәге затлар, шулай ук яше һәм сәламәтлеге аркасында хайваннарның хәрәкәтен контрольдә тота алмаган һәм йөртү вакытында аларның агрессиясен булдырмый кала алмаган затларга хайваннарны йөртергә;

-14 яше тулмаган затларга, кечкенә этләрне йөртүне исәпкә алмаганда, этләрне урамда йөртергә;

-йорт хайваннарын һәм кошларын балкон, лоджияләрдә, торак йортларның гомуми файдалану урыннарында (чиктәш фатирлар коридорлары, баскыч, чарлак, подвал һәм башка ярдәмче биналарда) даими асрау;

- йорт хайваннарының җирлек территориясендә моның өчен билгеләнгән урыннардан тыш җирләрдә, махсус чаралар үткәрү урыннарыннан тыш (күргәзмә) булуы.

183. Йорт хайваннарының кошлары хуҗаларының бурычлары:

-хайван авыруларын кисәтү, терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария таләпләренә җавап бирүен тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймау, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын күрү;

-хайваннарның асралу урынын даими контрольдә тоту;

-хайваннарның чирләгән һәм күпләп үлгән, үзләрен сәер тоткан очрагында кичекмәстән ветеринария оешмаларына хәбәр итәргә. Алар килгәнче авыру хайваннарны аерып ябарга;

-ветеринария белгечләре таләбе буенча диагностика тикшеренүләре үткәрү, саклану прививкалары ясау һәм дәвалау профилактика эшләре өчен хайваннарны тапшыру.

184. Үлгән терлекләрне күмү махсус билгеләнгән урында специальләшкән оешма тарафыннан башкарыла.

185. Үз территорияләрендә каравыл этләре тоткан оешмалар бурычлы:

-этләрне гомуми нигезләрдә теркәргә;

-этләрне ныклы бәйдә тотарга;

-килүчеләрнең хайваннар янына үтү мөмкинлеген булдырмаска;

- этләрне яхшылап коймаланган территориядә эш беткәннән соң гына яки территориягә кергәндә кисәтү язуы булган, гомуми файдаланудагы территориядән аерып коймаланган очракта гына бәйдән ычкындырырга;

186. Җәмәгать урыннарында булган күзәтүчесез хайваннар тотып алынырга тиеш.

187. Күзәтүчесез хайваннарны тотып алу җирле үзидарә органнары белән төзелгән килешү буенча специальләшкән предприятие яки башка зат тарафыннан башкарылырга мөмкин.

188. Карауачысыз хайваннарны тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру хайваннарга карата кешелекле мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларынна нигезләнеп башкарыла.

189. Рөхсәт ителми:

-суд карарыннан башка фатирлар һәм шәхси йортлар территорияләреннән хайваннарны тартып алу;

-кибет, аптека, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре һ.б. янында этләрне бәйдән ычкындыру;

- ветеринар киңәшеннән башка алдавычлар һәм башка аулау чаралары куллану.

## IX. Кагыйдәләр үтәлешен контрольдә тоту

190. Физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар җирлек территориясен төзекләндерү буенча әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

191. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә (федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган нормаларны һәм кагыйдәләрне үз эченә алган, аларны үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә җаваплылык билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) җаваплылыкка тартыла.

192. Төзекләндерү өлкәсендәге закон таләпләрен һәм муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен җаваплылыкка тарту әлеге таләпләрне үтәүдән һәм ясалган җитешсезлекләрне бетерүдән азат итми.

Биектау муниципаль районы
Иске-Казан авыл җирлеге Советының
2019 нчы елның ______________
______
номерлы карарына
2 нче номерлы

Кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге гражданнарының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проекты буенча фикер алышуда катнашу һәм фикер алышына торган проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советының карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре :

1.1. территорияне төзекләндерү Кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләрне карау буенча махсус комиссия рәисе тарафыннан язма рәвештә кабул ителә, ә ул булмаганда – комиссиянең бер әгъзасы тарафыннан.

1.2. территорияне төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча гражданнарның тәкъдимнәре территорияне төзекләндерү Кагыйдәләренә өстәмәләр һәм үзгәрешләрнең төзек текстын тәшкил итәргә, гражданин тарафыннан үзенең Ф.И.А.и., яшәү урыны адресын күрсәтеп имзаланырга тиеш.

1.3. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертүче гражданинга махсус комиссия рәисе  яисә комиссия әгъзасы тарафыннан имзаланган текстны алу турында язмача раслау тапшырыла .

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча махсус комиссия тарафыннан тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр почта аша алынган очракта, адресатка тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр алыну турында язма рәвештә почта аша җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр телефон аша кертелсә  - махсус комиссия рәисе яки махсус комиссия әгъзасы телефон аша гражданинга тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр алынуын раслый. Бу вакытта гражданинның Ф.И.А.и. һәм

аның яшәү урыны адресы язып алына.

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның барлык тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре махсус журналда (тегелгән һәм номерланган) теркәләләр, гражданнарның тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен кабул иткән зат тарафыннан расланган кәгазьдә яки телефон язмаларындагы тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре аңарга кушымта булып тора.

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Иске-Казан авыл җирлеге” территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында” Иске-Казан авыл җирлеге Советы карары проекты буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр түбәндәге адрес буенча: 422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клубная урамы, 4 нче йорт, тел.70-700, Иске-Казан авыл җирлеге Советында шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала көн саен 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр 2020 нче елның ______________ кадәр кабул ителә.